РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 138**

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль
районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү
һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» муниципаль
программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 24 ноябрендәге 772 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» муниципаль программасын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесенең
10.02.2020 елның 138 номерлы карары
белән расланган

**«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» муниципаль программасы (алга таба – Программа)**

**Паспорт**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның заказчысы | «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге |
| Программаны эшләүчеләр | Кукмара муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе;<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча район комиссиясе;<br>Кукмара муниципаль районының террорчылыкка каршы комиссиясе;<br>Кукмара муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе<br>Кукмара муниципаль районында халыкның тормыш, хезмәт дәрәҗәсен күтәрү, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия |
| Программаның максаты: | Кукмара муниципаль районында җинаятьчелеккә каршы торуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру, җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1. Кукмара муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү;<br>2. Юл-транспорт һәлакәтләреннән (алга таба – ДТП) үлүчеләр санын һәм зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү;<br>3. Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның |

<table>
<tr><td></td><td>тормыш һәм тынычлык дәрәҗәсен, Кукмара муниципаль районында экстремизмга һәм терроризмга каршы тору, профилактикалау һәм аларның күренешләрен кисәтү нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү;<br>4. Кукмара муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм медицинадан тыш куллану масштабларының кимүе.<br>5. Законсыз эшмәкәрлеккә каршы торуны оештыру һәм профилактикалау һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлеген киметү.</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары</td><td>2018 – 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программалар исемлеге</td><td>1. «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программасы»<br>2. «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасы<br>3. «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау»<br>4. «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы халкы арасында наркоманияне профилактикалау»<br>5. «2018 – 2020 елларга законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенә каршы тору һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлеген киметү»</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүленеп, Программаны финанслау күләме</td><td>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 11 079,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>ТР Кукмара муниципаль районының җирле бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2018</td><td>2 908,1</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>2 775,3</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>5 396,3</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>11 079,7</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны тормышка ашыру хокук бозуларны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттырырга, барлык милек рәвешләрендәге предприятие, учреждение, оешмаларны, шулай ук җәмәгатьчелек һәм халыкны хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлек оештыруга җәлеп итү; хокук бозуларны профилактикалауны норматив-хокукый җайга салуны тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.<br>Программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәгеләрне кыскартуга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 100 мең кешегә (саны) кылынган җинаятьләр санын 700 берәмлеккә кадәр;<br>- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма санын тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә 2% ка кадәр;<br>- элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма санын тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә 35% ка кадәр;<br>- урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган теркәлгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә җинаятьләрнең чагыштырма санын 16% ка кадәр;<br>- юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә, шул исәптән балалар арасында, үлем очракларын 2020 елга, 2017 ел белән чагыштырганда, 4,2 процентка киметү;<br>- 2020 елга социаль рискны 2017 ел белән чагыштырганда 5,5 процентка киметү;<br>- 2020 елга транспорт рискын 2017 ел белән чагыштырганда 3,61 процентка киметү;<br>- Кукмара муниципаль районы территориясендә толерантлык идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыру;<br>- яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту;<br>- халык, бигрәк тә яшьләр арасында җинаятьчелек, эчкечелек һәм наркомания дәрәҗәсен киметү; |

| | |
|---|---|
| | - милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә тотрыклылыкны саклап калу, милләтара мөнәсәбәтләр торышын уңай бәяләүче гражданнар өлешен арттыру. |

## I. Программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми характеристика, проблемалар һәм аларны чишү юллары

Төп стратегик максат – җинаятьчелеккә каршы торуның, җәмәгать тәртибен, милекне саклау сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү, җәмәгать куркынычсызлыгын һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шулай ук халык тарафыннан эчке эшләр органнарына ышанычны арттыру.

Бу максатка ирешү өчен беренчел бурычларның берсе – халыкның имин тормыш эшчәнлеге өчен шартлар тудыру, шәхесне, җәмгыятьне һәм дәүләтне җинаятьчел кул сузудан ышанычлы яклауны тәэмин итү.

Соңгы елларда тупланган куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча бурычларны тормышка ашыру тәҗрибәсе һәм практика, һичшиксез, бу эшкә комплекслы якын килүне кертү кирәклеге турында нәтиҗәгә китерә.

Хокук бозуларны профилактикалауның бөтен системасы эшенең нәтиҗәлелеген киметү озак вакытка исәпләнгән характерда булачак һәм халыкның куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә тискәре нәтиҗәләр алдагы елларда чагылыш табачак.

Болар барысы да хокук бозуларны профилактикалау проблемаларын хәл итүдә программа-максатчан якын килүне алга таба куллану зарурлыгына бәйле.

Районда 78 җирле дини оешма эшли: 73 мөселман (шул исәптән Кукмара мәдрәсәсе) һәм 5 православие мәхәлләсе. Теркәлгән чиркәүләрдә 2 гыйбадәт йорты һәм бер часовня эшли. Зур торак пунктларның храмнарында мәхәллә кешеләре өчен кичке һәм якшәмбе курслары эшли. Манзарас авылында 2 нче «Южный» мәчетен төзү планлаштырыла һәм Кукмара ш. Туеш микрорайонында яңа мәчет бинасы төзелеше тәмамланып килә. Мәчкәрә авылында 1791 елда төзелгән беренче җәмигъ мәчетен һәм Танькино авылында 1811 – 1822 елларда төзелгән Петр һәм Павел чиркәвен реставрацияләү дәвам итә.

Иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләрнең торышы, гомумән алганда, төрле социаль төркемнәр, милләт һәм дин вәкилләренең тотрыклылыгы, дустанәлеге, конструктив хезмәттәшлеге һәм аралашуы белән характерлана. Экстремистлык күренешләре күренми. Җирле халык традицион булмаган ислам тарафдарларына тискәре карый.

Хәзерге вакытта терроризм һәм экстремизмга каршы көрәш практикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый хәрәкәтләрнең һәм барлык гражданнарның тырышлыгын берләштерүне таләп итә.

Әлеге программа гражданнарның күп гасырлык үзара хөрмәт һәм тату яшәү традицияләре нигезендә этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә ярдәм итүгә юнәлдерелгән.

Наркотик чараларның законсыз әйләнеше белән шөгыльләнүче затларны ачыклау, шулай ук әлеге линия буенча җинаятьләрне ачыклау буенча эшне активлаштыру максатыннан, наркотикларның законсыз әйләнешенә катнашы булган затлар турында кергән оператив мәгълүматка анализ ясала, наркотикларның законсыз әйләнешен һәм наркопритоннарны ачыклау буенча даими рәвештә максатчан рейдлар үткәрелә. Рейдлар үткәрү барышында элек хөкем ителгән, шулай ук элек наркотик матдәләр кулланган кешеләрне наркотик матдәләр куллану фактына тикшерү үткәрелә.

Юл хәрәкәте иминлеге – Россия Федерациясенең мөһим социаль-икътисади һәм демографик бурычларының берсе. Автомобиль транспортында аварияләлек тулаем җәмгыятькә дә, аерым гражданнарга да зур матди һәм мораль зыян китерә. Юл-транспорт травматизмы эшкә яраклы кешеләрне җитештерү өлкәсеннән төшереп калдыруга китерә. Балалар һәлак була һәм инвалид кала.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү шәхси иминлекне тәэмин итү, демографик, социаль һәм икътисади проблемаларны хәл итү, тормыш сыйфатын күтәрү, төбәк үсешенә ярдәм итү илкүләм бурычларының бер өлеше булып тора.

Автомобиль транспорты белән бәйле аварияләр проблемасы соңгы унъеллыкта юл-транспорт инфраструктурасының җәмгыять һәм дәүләт ихтыяҗларына туры килмәве, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү системасының җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәве һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның бик түбән дисциплинасына бәйле рәвештә аеруча кискенләшә бара.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары. Программаның көтелгән ахыргы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны тормышка ашыруның максаты – Кукмара муниципаль районында җинаятьчелеккә каршы торуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру, җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенә каршы тору һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлеген.

Программаның максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

- Кукмара муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү;
- юл-транспорт һәлакәтләреннән үлүчеләр һәм юл-транспорт һәлакәтләреннән зыян күрүчеләр санын киметү;
- Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче

гражданнарның тормыш һәм тынычлык дәрәҗәсен, экстремизмга һәм терроризмга каршы тору, профилактикалау һәм аларның күренешләрен кисәтү нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү;

- наркотикларны законсыз тарату һәм медицинага кагылышсыз рәвештә куллану масштабларын киметү;
- район халкы арасында алкоголь продукциясен чамадан тыш куллану масштабларын киметү һәм алкоголизмны профилактикалау.
- законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенә каршы торуны профилактикалау һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлеген киметү.

Программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге юнәлештәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

- Кукмара муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе;
- зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләре санын һәм юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны кимү;
- терроризмга һәм экстремизмга каршы тору һәм район территориясендә яшәүче гражданнар тормышын яклау;
- хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү буенча эш нәтиҗәлелеген арттыру.

## III. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2018 – 2020 елларда районның җирле бюджеты акчалары хисабына Программаны финанслауның гомуми күләме 11 079,7 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
(мең сум)

| Ел | Районның җирле бюджеты акчалары күләме |
|---|---|
| 2018 | 2 908,1 |
| 2019 | 2 775,3 |
| 2020 | 5 396,3 |

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм, район бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм нәтиҗәлелеген бәяләү

Программа үтәлешен планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольне ел саен максатчан күрсәткечләрне һәм программа чараларына чыгымнарны, Программаны тормышка ашыру

механизмын һәм башкаручылар составын тәгаенли, чараларны үтәү өчен җаваплы кешеләрдән Программаны үтәү барышы турында мәгълүмат соратып ала торган Кукмара муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе; Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча район комиссиясе; Кукмара муниципаль районының терророрчылыкка каршы комиссиясе; Кукмара муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе гамәлгә ашыра.

Программаны тормышка ашыру Программа чараларының аларны үтәү сроклары, бюджет ассигнованиеләре, шулай ук чыгымнар турында мәгълүмат күрсәтелгән исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә башкарыла.

Программаны тормышка ашыруның бөтен чорында нәтиҗәлелеген бәяләү 2020 елга Программаны үтәү нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары буенча күрсәткечләрне исәпкә алып үткәрелә.

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору»
10.02.2020 ел 138 номерлы Программага
1 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеген оештыру» Ярдәмче программасы**

## ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | 2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеген оештыру (алга таба – 1 нче Ярдәмче программа) |
| 1 нче Ярдәмче программаның җаваплы башкаручысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 1 нче Ярдәмче программада катнашучылар | - Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге;<br>- Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;<br>ТР Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе;<br>- Дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе «Кукмара үзәк район хастаханәсе»;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;<br>- ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе»;<br>- «Кукмара районында халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;<br>- Федераль казна учреждениесе Кукмара районы филиалы Җәзаларны үтәтү Федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсенең җинаять төзәтү инспекциясе;<br>Кукмара районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |
| 1 нче Ярдәмче программа | Хокук бозуларны, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын профилактикалау системасын ныгыту, бу |

| | |
|---|---|
| максаты | эшчәнлеккә җирле үзидарә органнарын, җәмәгать формированиеләрен һәм халыкны җәлеп итү, хокук бозуларны профилактикалауда һәм җинаятьчелеккә каршы көрәштә җирле үзидарә органнарының ролен һәм җаваплылыгын арттыру |
| 1 нче Ярдәмче программаның бурычлары | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең киметү;<br>иң беренче чиратта эчкечелек, алкоголизм, наркомания, җинаятьчелек, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге, законсыз миграция белән көрәшкә юнәлдерелгән хокук бозуларны профилактикалау буенча эшне активлаштыру;<br>иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү;<br>халыкка, барыннан да элек яшьләргә һәм мәктәп яшендәге балаларга әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү;<br>хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының норматив хокукый базасын камилләштерү;<br>хокук бозуларны кисәтү мәсьәләләрендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү;<br>барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрне хокук бозуларны кисәтүгә җәлеп итү;<br>гражданнарның хокукый хәбәрдарлыгы һәм хокукый культурасы дәрәҗәсен күтәрү;<br>эчке эшләр органнарының дежур частьләренең гражданнарның хокук бозулар турында гаризаларына һәм хәбәрләренә оператив җавап бирүе;<br>җәмәгать урыннарын алардагы хәлләрне контрольдә тотуның техник чаралары белән тәэмин итү;<br>урамнарда һәм җәмәгать урыннарында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү;<br>экстремистлык настроениеләрен һәм күренешләрен, милли ызгышны, раса һәм дини түземсезлекне профилактикалау;<br>хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү |
| 1 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру | 2018 – 2020 еллар |

<table>
<tr><td>вакыты һәм этаплары</td><td></td></tr>
<tr><td>1 нче Ярдәмче программаны финанслауның еллар һәм чыганаклар буенча бүленгән күләме</td><td>2018 – 2020 елларда 1 Ярдәмче программа чараларын үтәүгә финанс чыгымнары Кукмара муниципаль районы бюджеты (алга таба – район бюджеты) хисабыннан 1 581,5 мең сум күләмендә планлаштырыла.<br>
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Кукмара муниципаль районының бюджет акчасы (мең сум)</th></tr>
<tr><td>2018</td><td>540,1</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>520,1</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>521,3</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>1 581,5</td></tr>
</table>
Моннан тыш, түбәндәге чыгымнар да күздә тотыла:<br>
- бюджеттан тыш чыганаклар акчалары<br>
- гамәлдәге законнар белән тыелмаган башка чыганаклардан акчалар<br>
Күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелә торган акчалар күләме фаразланган характерга ия һәм Программа чаралары исемлеген, ирешелгән нәтиҗәләр нигезендә аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын төгәлләштерүне исәпкә алып, тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштырганда билгеләнгән тәртиптә ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>1 нче Ярдәмче программаның иң мөһим максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре</td><td>1 нче Ярдәмче программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:<br>
- җинаятьләрнең саны (динамикасы);<br>
- тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма саны;<br>
- тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма саны;<br>
- теркәлгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә урамнарда кылынган җинаятьләрнең чагыштырма саны;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| 1 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | 1 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>хокук бозуларны профилактикалау буенча дәүләт системасының нәтиҗәлелеген арттырырга, хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга предприятиеләрне, учреждениеләрне, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларны, шулай ук иҗтимагый оешмаларны җәлеп итәргә;<br>хокук бозуларны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны тәэмин иәргә;<br>Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне яхшыртырга;<br>җәмәгать урыннарында, шул исәптән урамнарда кылынган җинаятьләрнең гомуми санын 2017 елдагы 27,7% тан 2020 елда 25,7% ка кадәр киметергә;<br>балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләр артуны булдырмау буенча профилактик чараларны дәвам итәргә;<br>рецидив җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә, ягъни элек җинаять кылган затлар кылган җинаятьләрнең чагыштырма санын тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми саныннан 2017 елдагы 32,9% тан 2020 елда 30,9% ка кадәр киметергә;<br>мөлкәти һәм икътисади җинаятьләр санын киметергә;<br>«көнкүреш» җинаятьчелек дәрәҗәсен киметергә, ягъни көнкүрештә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма санын тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми саныннан 2017 елдагы 38,3% тан 2020 елда 36,3% ка кадәр киметергә;<br>исерек хәлдә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма санын тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми саныннан 2017 елдагы 61,7% тан 2020 елда 58,4% ка кадәр киметергә;<br>наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләр артуга юл куймаска;<br>миграцион агымнарны контрольдә тотуны көчәйтергә, законсыз мигрантлар санын киметергә;<br>халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен арттырырга. |

## 1. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программалы хәл итүнең максатка ярашлылыгы

Татарстан Республикасы Президенты Указларын һәм Татарстан Республикасы законнарын, федераль һәм республика программаларын, шул исәптән җинаятьчелеккә каршы көрәш, наркотиклаштыруны профилактикалау, эшсез халыкны эш белән тәэмин итүгә һәм социаль яклауга ярдәм итү, яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча да гамәлгә ашыру, шулай ук полициянең участок уполномоченныйлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм аларны социаль-хокукый яклау дәрәҗәсен күтәрү буенча күрелә торган чаралар Кукмара муниципаль районында җәмәгать куркынычсызлыгы торышын тотрыкландыруга уңай йогынты ясый һәм билгеле бер дәрәҗәдә ярдәм итә.

Кабул ителгән һәм гамәлгә ашырыла торган «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 26.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 197-ФЗ номерлы федераль законнардан, Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 8 апрелендәге ПУ-127 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәте Стратегиясе, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законыннан,

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законыннан, «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы№ номерлы, «Татарстан Республикасы территориясендә әзер продукция күләменең 15 процентган артыгы этил спирты булган алкогольле продукцияне ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары хакында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарыннан, «Татарстан Республикасында алкоголь продукциясен, сыра, тәмәкене чамадан тыш куллануны киметү һәм халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарыннан, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауны көчәйтү буенча өстәмә чаралар турында» 2000 елның 24 маендагы ПУ-369 номерлы

Татарстан Республикасы Президенты Указы, «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Дәүләт программасын раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карарыннан уңай нәтиҗә көтелә.

Җәмәгать куркынычсызлыгының торышына гражданнарның аерым социаль җайлашмаган категорияләре, алар арасында караучысыз балалар һәм яшүсмерләр, балигъ булмаган хокук бозучылар һәм irектән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар, шулай ук әлеге категория гражданнарны реабилитацияләүнең чын мәгънәсендә нәтиҗәле формалары булмау аеруча тискәре йогынты ясый. Күрелә торган чараларның шактый өлеше таркау (берләшмәгән) һәм тар ведомство характерына ия.

2017 елның 8 ае нәтиҗәләре буенча 173 җинаять теркәлгән, бу узган елның шул ук чоры (230) белән чагыштырганда 24,8% ка кимрәк (ТР буенча – 9,3%).

Үсеш:

- аңлы рәвештә сәламәтлеккә үлемгә китергән авыр зыян салу – 100,0% ка, 0 дән 1 гә кадәр (ТР буенча – 22,5%);
- бакча йортларыннан һәм дачалардан урлау – 100,0% ка (2 тапкыр), 1 дән 2 гә кадәр (ТР буенча – 23,6%);
- талаулар – 100,0% ка (2 тапкыр), 4 тән 8 гә кадәр (ТР буенча – 19,8%);
- ут төртү яки шартлату юлы белән мөлкәтне алдан уйлап юкка чыгару яки зыян китерү фактлары – 100,0% ка, 0 дән 2 гә кадәр (ТР буенча – 14,8%).

узган елның шул ук чоры дәрәҗәсендә калган сан:

- сәламәтлеккә аңлы рәвештә авыр зыян салу – 5 (ТР буенча – 19,4%);
- складлардан, базалардан, кибетләрдән һәм башка сәүдә нокталарыннан урлаулар – 1 (ТР буенча – 11,1%);
- талау – 2 (ТР буенча – 28,5%).

Аеруча авыр һәм авыр җинаятьләрнең чагыштырма саны 17,3% тәшкил итте (30, узган елның шул ук чорында – 16,5%), бу категория буенча уртача күрсәткечтән (18%) 0,7% ка кимрәк.

Икътисади юнәлештәге барлыгы 6 җинаять ачыкланган, бу узган елның шул ук чорындагыдан (19) 68,4% ка (3,2 тапкыр) кимрәк (ТР буенча -26,6%). Наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле – 6 җинаять, бу узган елның шул ук чорындагыга (3) караганда 100,0% ка (2 тапкыр) күбрәк (ТР буенча – +8,0%). Наркотик исереклеге халәтендә кылынган җинаятьләрнең чагыштырма саны тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми санының 0,7% ын тәшкил итте (узган елның шул ук чорында – 0%), бу категория буенча уртача күрсәткечтән (0,6%) 0,1% ка артыграк.

Җәмәгать урыннарында 48 җинаять теркәлгән, бу узган елның шул ук чорындагыга (60) караганда 20,0% ка кимрәк (ТР буенча – 16,0%).

Җинаятьчелекнең гомуми структурасында аларның чагыштырма саны 27,7% тәшкил итте (узган елның шул ук чорында – 26,1%), бу категория буенча уртача күрсәткечтән (20,1%) 7,6% ка күбрәк. Урамнарда 37 җинаять теркәлгән, бу узган елның шул ук чорындагыга (45) караганда 17,8% ка кимрәк (ТР буенча – 18,5%). Җинаятьчелекнең гомуми структурасында аларның чагыштырма саны 21,4% тәшкил итте (узган елның шул ук чорында – 19,6%), бу категория буенча уртача күрсәткечтән (13,6%) 7,8% ка күбрәк.

Балигъ булмаганнарга карата кузгатылган җинаять эшләре буенча (тикшерелгән җинаятьләр саны 1 дән 6 га кадәр яисә 500,0% ка (6 тапкыр) арткан (ТР буенча – 29,8%). Тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә аларның чагыштырма саны 4% тәшкил итте (узган елның шул ук чорында – 0,6%), бу категория буенча уртача күрсәткечтән (3,3%) 0,7% ка артыграк.

Җинаятьчелеккә каршы көрәш практикасы бүгенге көндә җирле үзидарә органнарының һәм иҗтимагый хәрәкәтләрнең тырышлыгын таләп итә. Хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен хәл итүгә тиешле финанс һәм матди-техник чаралар белән ныгытылган комплекслы якын килүне тәэмин иткән очракта гына тамырдан үзгәрешкә ирешергә мөмкин. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бу өлкәдә хәлне яхшыртуга ирешү әлеге 1 нче Ярдәмче программа чараларына һәм муниципаль, һәм дәүләт ярдәме күрсәткәндә мөмкин.

## 2. 1 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның төп максатлары һәм бурычлары, сроклары һәм этаплары

1 нче Ярдәмче программаның төп максатлары – хокук бозуларны профилактикалау системасын формалаштыру, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын ныгыту, бу эшчәнлеккә дәүләт органнарын, җәмәгать формированиеләрен һәм халыкны җәлеп итү, хокук бозуларны профилактикалау һәм җинаятьчелеккә каршы көрәштә җирле үзидарә органнарының ролен һәм җаваплылыгын арттыру.

1 нче Ярдәмче программа түбәндәге бурычларны билгели:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең кимүе;

иң беренче чираттта эчкечелек, алкоголизм, наркомания, җинаятьчелек, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге, законсыз миграция белән көрәшкә юнәлдерелгән хокук бозуларны профилактикалау буенча эшне активлаштыру;
иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләү;

халыкка, барыннан да элек яшьләргә һәм мәктәп яшендәге балаларга әхлакый тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү;

хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының норматив хокукый базасын камилләштерү;

хокук бозуларны кисәтү мәсьәләләрендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү;

барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук иҗтимагый берләшмәләрне хокук бозуларны кисәтүгә җәлеп итү;

гражданнарның хокукый хәбәрдарлыгы һәм хокукый культурасы дәрәҗәсен күтәрү; Эчке эшләр органнарының дежур частьләренең гражданнарның хокук бозу турында гаризаларына һәм хәбәрләренә оператив җавап бирүе;

җәмәгать урыннарын алардагы хәлләрне контрольдә тотуның техник чаралары белән тәэмин итү;

урамнарда һәм җәмәгать урыннарында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау эшен оптимальләштерү;

экстремистлык настроениеләрен һәм күренешләрен, милли ызгышны, раса һәм дини түземсезлекне профилактикалау;

хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү

1 нче Ярдәмче программа 2018 – 2020 еллар дәвамында тормышка ашырыла.

## 3. 1 нче Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

1 нче Ярдәмче программаны Кукмара муниципаль районы бюджеты исабына финанслауның гомуми күләме 1 581, 5 мең сум тәшкил итә.

| Ел | Кукмара муниципаль районының бюджет акчасы (мең сум) |
|---|---|
| 2018 | 540,1 |
| 2019 | 520,1 |
| 2020 | 521,3 |
| Барлыгы: | 1 581,5 |

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелгән акчалардан файдалану күздә тотыла.

1 нче Ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында һәм Кукмара муниципаль районының тиешле елга бюджет проектын формалаштырганда, Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып, билгеләнгән тәртиптә ел саен анықланырга тиеш.

## 4. 1 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

1 нче Ярдәмче программаның үтәлешен планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм гомуми контрольдә тоту Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла, ул ел саен 1 нче Ярдәмче программа чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, 1 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын аныклый, чараларны үтәү өчен җаваплы субъектлардан 1 нче Ярдәмче программаның үтәлеше турында мәгълүмат соратып ала.

1 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

1 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен җаваплы башкаручылар 1 нче Ярдәмче программаның заказчы-координаторына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр чаралар үтәлеше һәм чараларны башкаручыларга тиешле бюджетлардан бүлеп бирелә торган акчаларның үзләштерелүе турында арта баручы нәтиҗә белән һәм тулаем алганда хисап елына мәгълүмат тапшыралар.

1 нче Ярдәмче программага үзгәрешләр кертү 1 нче Ярдәмче программа чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте йөкләмәләрен билгеләнгән таләпләр нигезендә үтәү йөзеннән гамәлгә ашырыла.

Кукмара муниципаль районының хокук бозуларны профилактикалау буенча ведомствоара комиссиясе утырышларында программа чараларын үтәү һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеген даими карау планлаштырыла, аларда хокук бозуларны профилактикалау субъектлары җитәкчеләре – 1 нче Ярдәмче программаны башкаручылар тыңланачак. Ел саен 1 февральгә кадәр Кукмара муниципаль районы Советы утырышында 1

нче Ярдәмче программаның узган елдагы үтәлеше турында йомгаклау доклады тәкъдим ителә.

## 5. 1 нче Ярдәмче программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

1 нче Ярдәмче программа чараларын үтәү түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

- хокук бозуларны профилактикалау системасының нәтиҗәлелеген арттыру, хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлекне оештыруга барлык профилактика субъектларын, җәмәгатьчелекне җәлеп итү;

хокук бозуларны профилактикалауны норматив хокукый җайга салуны тәэмин иәргә;

-законга буйсынучан гражданин яшәү рәвешен формалаштыру өчен мәгълүмати-пропаганда эшчәнлеген тулырак кулланырга;

халыкның хокук саклау органнарына ышаныч дәрәҗәсен арттырырга;

- кылына торган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр санын киметү;

- урамнарда һәм башка җәмәгать урыннарында криминоген хәлне тотрыкландырырга һәм әлеге төр җинаятьләрне этаплап киметә башларга;

- балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган хокук бозуларны киметүне дәвам итәргә;

- элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган хокук бозуларны киметүне дәвам итәргә.

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау эшчәнлеген оештыру» Ярдәмче программасына кушымта

| Төп<br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| **Максат: Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау эшчәнлеген камилләштерү** | | | | | | | | | | |
| **1 нче бурыч. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсенең киметү** | | | | | | | | | | |
| 1.1. Татарстан Республикасы җәмәгать куркынычсызлыгы һәм хокук саклау органнары эшчәнлеге проблемаларына бәйле мәсьәләләр буенча муниципаль районда социологик тикшеренүләр үткәрүгә булышлык күрсәтүне оештыру | ТР Иҗтимагый палатасы, муниципаль район Советының Иҗтимагый палатасы, ОМС | 2018 – 2020 еллар | 100 мең кешегә кылынган җинаятьләр саны, берәмлек | 1316,0 | 1306,0 | 1296,0 | 1286,0 | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 1.2. Халыкта законсыз саклана торган корал һәм сугыш кирәк-яраклары тапшыруны стимуллаштыру | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.3. Коррупциягә, ялган монеталылыкка, алкогольле һәм спиртлы продукциянең законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча оператив-профилактик чаралар үткәрергә, аларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту, җәмәгать урыннарында агитация-реклама материаллары | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| урнаштырырга | бүлеге | | | | | | | | | |
| 1.4. Хокук бозуларны профилактикалауга юнәлдерелгән пиар-акцияләр оештырырга, аларның барышын һәм нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртырга | «Татмедиа» филиалы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), ММИ (килешү буенча), УДМС | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 1.5. Медицина экспертизасының заманча ысулларын гамәлгә кертергә, белгечләрне укытырга, өзлексез эшләү өчен чыгым материаллары белән тәэмин итәргә. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 0,1 | 0,1 | 0,1 |
| | | | | | | | | - | - | - |
| 1.6. Контроль буенча үткәрелә торган планлы чаралар кысаларында психоактив матдәләр булган продукцияне ачыклау һәм әйләнештән алу эшен дәвам итәргә | Роспотребнадзорның ТР буенча территориаль бүлеге (килешү буенча),<br><br>ТР буенча РФ УФСКН (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 1.7. Татарстан Республикасы Кукмара районы территориясендә тәмәке эшләнмәләрен ваклап сатучы хуҗалык итүче субъектларны, билгеләнгән таләпләрне бозып, тәмәке сату фактларын ачыклап, контрольлек итәргә | Роспотребнадзорның ТР буенча территориаль бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.8. Алкогольле һәм спиртлы продукциянең легаль булмаган әйләнешен кисәтүгә, балигъ булмаганнар тарафыннан тәмәке әйберләре, алкогольле һәм спиртлы продукция куллану фактларына, контрафакт һәм фальсификацияләнгән товарларны әйләнештән алуга юнәлдерелгән оператив-профилактик чаралар үткәрү; | ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль бүлеге,<br><br>Роспотребнадзорның ТР буенча территориаль бүлеге (килешү буенча), ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.9. Дини-милли экстремизмга каршы юнәлдерелгән мәгълүмати-пропаганда эшчәнлеген оештырырга | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), Мәҗбүри медицина | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| | иминияте | | | | | | | | | |
| 1.10. Объектларда һәм якын-тирә территориядә видеокүзәтү урнаштыру буенча шәхси эшмәкәрләр һәм иҗтимагый оешмалар белән эшне оештырырга. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), Мәҗбүри медицина иминияте | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.11. Халык арасында гражданнарга карата хокук бозулар кылган вакытта эш итү тәртибе турында белешмәлекләр (листовкалар) һәм социаль мошенниклык профилактикасы буенча башка материалларны эшләү һәм тарату. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге, Мәҗбүри медицина иминияте | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| **2 бурыч. Балигъ булмаганнар белән эшләүнең инновацион формаларын һәм методларын куллану, балалар һәм яшьләргә әхлакый һәм патриотик тәрбия бирүне активлаштыру һәм камилләштерү** | | | | | | | | | | |
| 2.1. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре арасында ел саен үткәрелә торган республика конкурсын (муниципаль этап) үткәрүне оештырырга. Аларның эшчәнлеген матди кызыксындыру системасын эшләргә. | КДН һәм ЗП | 2018 – 2020<br><br>еллар | тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган | 5,6 | 5,5 | 5,4 | 5,3 | 3,0 | 3,0 | 3,0 |
| 2.2. «Балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать | КДН һәм ЗП | 2018 – 2020 | | | | | | - | - | - |

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| тәрбиячесе» еллык республика конкурсында катнашу | | еллар | җинаятьләрнең чагыштырма саны, процентларда | | | | | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 2.3. Тематик лекторийлар, сыйныф сәгатьләре үткәрү, радиода, газетада яшүсмерләр арасында җинаятьчелек, имин булмаган гаиләләр, балигъ балигъ булмаганнарга карата хокукка каршы кул сузу, караучысызлык һәм тәрбиячесезлек, эчкечелек, наркомания һәм токсикомания, балалар арасында юл-транспорт травматизмы һ. б. мәсьәләләр буенча мәкаләләр чыгару. | Мәгариф идарәсе, Үзәк район хастаханәсе, халыкны социаль яклау бүлеге, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге | 2018 – 2020<br><br>еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.4. Сәламәтләндерү учреждениеләре базасында дәүләтнең аерым кайгыртуына мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсус медицина-психологик тернәкләндерү программаларын тормышка ашыру | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара районындагы ОСЗ, УДМС | 2014 – 2020<br><br>еллар | | | | | | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 2.5. Укучыларның девиант тотышын кисәтү буенча Татарстан Республикасы Кукмара районы гомуми белем бирү учреждениеләренең тәрбия эшләре буенча директор урынбасарларының методик эшләнмәләре конкурсын үткәрү | Мәгариф идарәсе | 2018<br><br>ел | | | | | | - | - | - |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 2.6 Социаль куркыныч хәлдәге балалар, ятим балалар, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен мәктәп яны лагерьларында, физкультура-ял һәм спорт учреждениеләрендә өстенлек оештырырга | Мәгариф идарәсе, Балалар иҗат үзәге, балалар-яшьләр иҗат үзәге, УДМС | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.7 социаль куркыныч хәлдә булган балаларны социаль әһәмиятле эшчәнлеккә актив җәлеп итүгә юнәлдерелгән грант нигезендә проектлар конкурсларында катнашу | Мәгариф идарәсе Белем бирү учреждениеләре | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.9. проектын тормышка ашыруны дәвам итәргә Район мәгариф учреждениеләрендә «Мәктәп килештерү хезмәте» | Мәгариф идарәсе Белем бирү учреждениеләре | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.10 Хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә эшләүче җитәкчеләр һәм педагогик хезмәткәрләр өчен, практикларны, хакимият органнары вәкилләрен, хокук саклау органнары хезмәткәрләрен җәлеп итеп, квалификация күтәрү курслары, төрле фәнни-гамәли чаралар оештырырга | Мәгариф идарәсе социаль-гуманитар белем бирү үзәге белән берлектә (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 2.11 Яшүсмерләр-яшьләр арасында экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча тәрбия өлкәсе кадрларының квалификациясен күтәрү курсларында катнашу | Мәгариф идарәсе Белем бирү учреждениеләре | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 2.12 Республика конкурсларының муниципаль этапларын үткәрү:<br><br>үсеп килүче буынның рухи-әхлакый культурасын формалаштыруга, җәмгыятьне, әйләнә-тирә дөньяны толерант итеп кабул итүгә юнәлтелгән, шул исәптән яшьләргә мәдәният, төрле этнослар тарихы турында мәгълүмат җиткерүне дә кертеп, социаль әһәмиятле проектлар;<br><br>Татарстан Республикасы Кукмара районы белем бирү учреждениеләрендә интернациональ дуслык клубларын үстерү буенча иң яхшы эшкә | Мәгариф идарәсе, Кукмара районы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2018 – 2020<br><br>еллар | | | | | | 3,0 | 3,0 | 3,0 |
| 2.13. Үткәрергә:<br><br>ел саен үткәрелә торган «Аҗаган» хәрби-патриотик уены;<br><br>яшьләр, шул исәптән Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлегенең ПДНда профилактик исәптә торучы затлар өчен хәрби-спорт, патриотик чатыр лагерьлары;<br><br>гражданнарның, белем бирү оешмалары укучыларының тыл хезмәтчәннәре, Бөек Ватан сугышы ветераннары, хәрби хәрәкәтләрдә һәм локаль конфликтларда катнашучылар, ТР РОГО (ДОСААФ) вәкилләре белән очрашулары;<br><br>ел саен Призывник көне | УДМС, УО<br><br>ТР ДОСААФ (килешү буенча), Кукмара районы буенча ТР ВК (килешү буенча), ЦДТ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 8,0 | 8,0 | 8,0 |

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 2.14. Мәктәп, югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучыларына идея-әхлакый тәрбия бирү, хокук бозуларны профилактикалау, хокук аңын формалаштыру, буенча кинофильмнар, кинодәресләр күрсәтүне оештыру | УК, УО | 2018 – 2020 , квартал саен | | | | | | - | - | - |
| 2.15 Мәктәп һәм сыйныф укучылары белән Спартакиада, ярышлар, конкурслар, «куркынычсызлык мәктәбе» үткәрергә | Кукмара янгын-коткару гарнизоны (ТР буенча МЧС РФ по РТ) | | | | | | | - | - | - |
| 2.16. яшүсмерләр һәм яшьләр белән мәдәниятара һәм конфессияара диалогны үстерү, толерант тәртип күнекмәләренә өйрәтү буенча чаралар комплексын (слетлар, конференцияләр, семинарлар, форумнар, психологик һәм коммуникатив тренинглар) оештырырга | МДМСТ РТ | 2018 – 2020<br><br>еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.17 Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, мәктәп формированиеләрен, шул исәптән ирекле халык дружиналарын үстерү эшен оештыруны тәэмин итәргә. | Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча), Башкарма комитет, «Форпост» үзәге» МБУ | 2018 – 2020<br><br>еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.18 «Күңелсезләнмәүче ишегалды» җәйге (каникул) чорында балалар һәм яшүсмерләр белән яшәү урыны буенча эш оештырырга. | УДМС, «П/к «Ялкын», «Форпост» үзәге» МБУ | 2018 – 2020<br><br>еллар | | | | | | - | - | - |
| 2.19 Муниципаль хезмәткәрләрнең – гаилә иминлеге | ОМС | 2018 – 2020 | | | | | | 450,0 | 430 | 431,2 |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| буенча инспекторларның эшчәнлеген оештыру һәм аларны карап тоту | | еллар | | | | | | | | |
| **3 нче бурыч Хөкем ителүчеләрне иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат итүгә әзерләүне оештыру** | | | | | | | | | | |
| 3.1. «Кукмара районында халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе аша иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эшкә урнаштыру | ЦЗН | | тикшерелгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең чагыштырма саны; | | | | | - | - | - |
| 3.2. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү | ОСЗ | | | | | | | - | - | - |
| 3.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан кайткан затларны ресоциализацияләү буенча эшче төркем утырышларын үткәрү | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан кайткан затларны ресоциализациялəү буенча эшче төркем | | | | | | | - | - | - |
| 3.4. Татарстан Республикасы җинаять-башкарма системасы учреждениеләрендәге туберкулез белән авыручылар өчен дәвалау-диагностика чараларын үткәрүне оештырырга | «Кукмара РҮХ» ДАССУ, РТ буенча УФСИН (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 3.5. Хокук бозулар кылуга сәләтле психик тайпылышлар булган пациентларны «Сенсор бүлмәсе» җиһазлары ярдәмендә реабилитацияләүнең заманча ысулларын кертү | ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы, «Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |

<table>
<tr><td rowspan="2">Төп<br><br>чараларның исеме</td><td rowspan="2">Башкаручылар</td><td rowspan="2">Төп чараларны үтәү сроклары</td><td rowspan="2">Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре</td><td colspan="4">Индикатор күрсәткечләре</td><td colspan="3">Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум</td></tr>
<tr><td>2017 (база)</td><td>2018 ел</td><td>2019 ел</td><td>2020 ел</td><td>2018 ел</td><td>2019 ел</td><td>2020 ел</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td><td>10</td><td>11</td></tr>
<tr><td>3.6 балигъ булмаган балалары булган, шул исәптән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаган затларны социаль тернәкләндерү эшен оештырырга.</td><td>ОСПСиД, ЦЗН (килешү буенча)</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td colspan="4">4 нче бурыч. Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен заманча техник чаралар кертү</td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td>4.1 Зур Сәрдек, Күкшел, Мәмәшир, Ош-Юмья, Урта Комар, Каенлык, Починок-Кучук авыл җирлекләренә полиция участок пунктлары өчен биналар бүлеп бирү, аларны агымдагы яки капиталь ремонтлауны тәэмин итү.</td><td>ОМС</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td rowspan="3">урамнарда һәм җәмәгать урыннарында кылынган теркәлгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә җинаятьләрнең чагыштырма саны;</td><td rowspan="3">35,0</td><td rowspan="3">34,8</td><td rowspan="3">34,6</td><td rowspan="3">34,4</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>4.2 ел саен үткәрелә торган «Закон территориясе» конкурсын үткәрергә.<br><br>Җәмәгать тәртибен тәэмин итүгә, яшүсмерләргә һәм яшьләргә хокукый тәрбия бирүгә өлеш керткән предприятиеләр һәм оешмалар, уку йортлары һәм физик затлар арасында</td><td>Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), Мәҗбүри медицина иминияте, районның белем бирү оешмалары</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td>5,0</td><td>5,0</td><td>5,0</td></tr>
<tr><td>4.3 «Полициянең иң яхшы участок уполномоченные», «Иң яхшы профилактика отряды», «Иң яхшы халык дружинасы» исеменә еллык һөнәри осталык конкурслары</td><td>Россия Эчке эшләр министрлыгыны</td><td>2018 – 2020 еллар</td><td>30,0</td><td>30,0</td><td>30,0</td></tr>
</table>

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| үткәрүне оештырырга | ң Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), Мәҗбүри медицина иминияте | | | | | | | | | |
| 4.4. Халык арасында гражданнарга карата хокук бозулар кылган вакытта эш итү тәртибе турында белешмәлекләр (листовкалар) һәм социаль мошенниклык профилактикасы буенча башка материалларны эшләү һәм тарату. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге, Мәҗбүри медицина иминияте | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| **5 нче бурыч. Урамнарда хокук тәртибен тәэмин итү** | | | | | | | | | | |
| 5.1. «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кысаларында гражданнарны ирекле халык дружиналарына җәлеп итү, яшьләр, шул исәптән студентлар һәм эшче яшьләрнең хокук саклау хәрәкәтен үстерү | Мәҗбүри медицина иминияте (килешү буенча),<br><br>ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | - теркәлгән җинаятьләрнең гомуми исәбендә урамнарда кылынган җинаятьләрнең чагыштырма саны; | 23,9 | 23,8 | 23,7 | 23,6 | - | - | - |

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 5.2. Массакүләм мәгълүмат чараларында җәмәгать тәртибен саклауда ирекле катнашучы затларның уңай эш тәҗрибәсен һәм фидакарь гамәлләрен пропагандалауны гамәлгә ашыру | «Татмедиа» Филиалы, ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 5.3. Җинаятьләрне ачуда һәм аларны кылган затларны тоткарлауда ярдәм иткән, шулай ук полициягә үзенә йөкләнгән башка бурычларны үтәүдә ярдәм иткән өчен гражданнарга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түләүне гамәлгә ашыру | Эчке эшләр министрлыгы | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 5.4 Җәмәгать тәртибен саклау буенча иң яхшы яшьләр, эшче, студентлар һәм мәктәп формированиеләре буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсында, Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләренең республика слетларында һәм конференцияләрендә катнашу | ТР УДМС «Форпост» район үзәге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | 8,0 | 8,0 | 8,0 |
| | Мәгариф идарәсе | | | | | | | | | |
| 5.5. Татарстан Республикасының «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр, студентлар һәм мәктәп формированиеләре үзәкләренең матди-техник базасын ныгыту, шул исәптән кием-салым, оргтехника, элемтә чаралары һәм спорт инвентарьлары белән тәэмин итү | УДМС, «Форпост» район үзәге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| Төп<br><br>чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (база) | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| 6. Социаль реклама проектларын, төрле җинаять һәм хокук бозуларны профилактикалау темасына социаль аудио-, видеороликлар һәм видеофильмнарны гамәлгә ашыру, аларны телетаршыруларда хокук саклау тематикасына һәм республика телерадиокомпанияләренең реклама блокларында даими трансляцияләүне оештыру | «Татмедиа» Агентлыгы,<br><br>ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча) | 2018<br><br>ел | | | | | | - | - | - |
| **БАРЛЫГЫ** | | | | | | | | 540,1 | 520,1 | 521,3 |

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның
_______________ ________ номерлы
карарына2 нче кушымта

«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ ИМИНЛЕГЕН АРТТЫРУ» ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга татарстан республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» (алга таба – 2 нче Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаны эшләү өчен нигез | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча район комиссиясе карары нигезендә эшләнгән |
| Ярдәмче программа координаторы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (килешү буенча) |
| Подпрограмманың муниципаль заказчысы | Кукмара шәһәр Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Кукмара муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлеге (алга таба – ЮХИДИ бүлеге), «Татарстан Республикасы юл хәрәкәте иминлеге фәнни һәм белем бирү программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт казна учреждениесенең Кукмара филиалы, «Кукмара үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 117 янгын сүндерү бүлеге» ФДКУ |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары | Ярдәмче программа-2 нең максатлары:<br>- зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү;<br>- юл-транспорт һәлакәтләреннән үлүчеләр санын киметү;<br>2 нче Ярдәмче программаның бурычлары:<br>- юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатыннан пропаганда системасын булдыру;<br>- балаларда юлларда куркынычсыз тәртип күнекмәләре формалаштыру;<br>- машина йөртү культурасын күтәрү;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең заманча системасын үстерү;<br>- транспорт чаралары белән идарә итүгә хокук алу өчен машина йөртүчеләрне әзерләү таләпләрен һәм мондый әзерлекне гамәлгә ашыручы автомәктәпләргә карата таләпләрне арттыру. |
| Максатчан күрсәткечләр һәм индикаторлар | 2 нче Ярдәмче программаның мөһим күрсәткечләре:<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны;<br>- юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны;<br>- социаль риск (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны – 100 мең кешегә);<br>- транспорт рискы (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны 10 мең транспорт чарасына). |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сроклары: | Ярдәмче программа-2 2018 – 2020 елларга исәпләнгән. |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Ярдәмче программа-2 не финанслауның гомуми күләме – 2018 – 2020 елларга 1 506,3 мең сум.,<br>шул исәптән: |

| Ел | Җирле бюджет акчалары, мең сум |
|---|---|
| 2018 | 0 |
| 2019 | 6,3 |
| 2020 | 1500,0 |
| Барлыгы | 1 506,3 |

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | - юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлем очраклары, шул исәптән балалар арасында, 2018 – 2020 елларга, 2012 ел белән чагыштырганда, 2,64 процентка киметү;<br>- 2018 – 2020 елларга социаль рискны 2012 ел белән чагыштырганда 3,5 процентка киметү;<br>- 2018-2020 елларга транспорт рискын 2012 ел белән чагыштырганда 0,33 процентка киметү. |

## I. 2 нче Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы

Юл хәрәкәте иминлеге – Россия Федерациясенең мөһим социаль-икътисади һәм демографик бурычларының берсе. Автомобиль транспортында авариялелек тулаем җәмгыятькә дә, аерым гражданнарга да зур матди һәм мораль зыян китерә. Юл-транспорт травматизмы эшкә яраклы кешеләрне җитештерү өлкәсеннән төшереп калдыруга китерә. Балалар һәлак була һәм инвалид кала.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү шәхси иминлекне тәэмин итү, демографик, социаль һәм икътисади проблемаларны хәл итү, тормыш сыйфатын күтәрү, төбәк үсешенә ярдәм итү илкүләм бурычларының бер өлеше булып тора.

Автомобиль транспорты белән бәйле аварияләр проблемасы соңгы унъеллыкта юл-транспорт инфраструктурасының җәмгыять һәм дәүләт

ихтыяҗларына туры килмәве, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү системасының җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәве һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның бик түбән дисциплинасына бәйле рәвештә аеруча кискенләшә бара.

Югары дәрәҗәдәге аварияләлек сәбәпләрен билгеләүче төп факторларга түбәндәгеләрне кертергә кирәк:

юл хәрәкәтендә катнашучыларның юл хәрәкәте куркынычсызлыгы таләпләрен күпләп үтәмәүләре, җәмгыять тарафыннан юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча чараларга җитәрлек дәрәҗәдә ярдәм итмәү, юл хәлен бәяләүдә ялгышлыкка китерүче машина йөртүчеләрне әзерләүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы, транспорт чаралары белән идарә иткән вакытта машина йөртүчеләрнең канәгатьләнмәслек дисциплинасы, игътибарсызлыгы һәм саксызлыгы;

юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларын техник яктан тәэмин итүнең җитешсезлекләре, беренче чиратта, юл хуҗалыгының, транспорт чараларының техник дәрәҗәсенә, юл хәрәкәтен оештыру чараларының заманча таләпләргә туры килмәве, юл-транспорт һәлакәтләрен соң ачыклауга һәм зыян күрүчеләргә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү системаларында артта калу.

Җәяүлеләр тарафыннан травмалар алуга китерә торган юл хәрәкәте кагыйдәләрен төп бозулар булып түбәндәгеләр кала: машиналар йөрү өлешен билгеләнмәгән урыннарында аркылы чыгу, транспорт чаралары яки транспорт чарасы аркасында күтелмәгәндә чыгу, тротуар булган очракта да машина юлыннан йөрү, торак пункттан читтә машина юлы буйлап юл уңаеннан йөрү һәм җәяүлеләрнең машина йөрү өлешендә исерек хәлдә булу. Иң зур куркынычы – җәяүлеләрнең машиналар йөрү өлешендә исерек хәлдә булуы.

2017 елның 1 сентябренә Кукмара районында 15679 берәмлек автотранспорт чарасы теркәлгән. Кукмара шәһәренең иң интенсив хәрәкәтле урамнары: Ленин, Ворошилов, Степан Разин, Октябрь, Гагарин, Магистраль, Ибраһимов урамнары, Эшче тыкрыгы, Чернышевский урамнары.

Хәрәкәт күп булган участокларда хәрәкәтне оештыруда светофорлар зур роль уйный. Хәзерге вакытта Кукмара шәһәре урамнарында дүрт светофор эшли, аларның 2 се иң күп санлы укучылы «Кукмара ш. т. п. Булатов исемендәге лицей» муниципаль белем бирү учреждениесе янында һәм Магистраль һәм Лобачевский урамнары чатында, Ленин урамында («Үзәк базар») урнашкан.

Кышкы чорда юл хәрәкәте иминлегенә җитди йогынты ясаучы мөһим факторларның берсе – урам-юл челтәренең торышы. Статистика күрсәткәнчә, юл-транспорт һәлакәтләренең 30% тан артыгы машиналар йөрү өлешен тиешенчә карап тотмау аркасында килеп чыга. Үткәрү сәләте кими, бу авария хәлләре

барлыкка килүгә, пассажирлар һәм йөк ташуларның нигезсез тоткарлануына китерә.

Автотранспорт чаралары санының шактый артуы урам-юл челтәренең үткәрүчәнлегенә, транспорт чараларын урнаштыруга тискәре йогынты ясый торган тагын бер проблеманы билгеләде. Административ һәм мәдәни-спорт учреждениеләре, сәламәтлек саклау учреждениеләре һәм сәүдә объектлары, Үзәк базар янында машиналарны вакытлыча саклау урыннары белән тәэмин итү проблемасы аеруча кискен тора. Мондый урыннарда транспорт чараларын урнаштыру өчен урыннар җитмәү машина йөртүчеләрне юл хәрәкәте кагыйдәләрен ачыктан-ачык бозып транспорт чараларын туктатырга мәҗбүр итә, бу урамнарның үткәрүчәнлек сәләте кимүгә һәм катлаулы хәлләр барлыкка килүгә китерә. Әйтик, көндезге сәгатьләрдә Кукмара шәһәренең Ленин («Үзәк базар») һәм Ворошилов («Үзәк район хастаханәсе») урамнары буенча хәрәкәт тулысынча диярлек тукталу дәрәҗәсенә җитә.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемасы халыкның иң киң катламнарының, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алмыйча хәл ителә алмый. Социаль-психологик иҗтимагый берләшмәләр нигезендә Халыкның киң массаларының үз-үзен тотышы һәм иҗтимагый аңын формалаштыру тәҗрибәсе кешеләрнең үз-үзләрен тотышы характерында массакүләм үзгәрешләргә исәп тотарга мөмкинлек бирә.

Районда балалар белән эшләүнең традицион формалары кулланыла:

- юл хәрәкәте иминлеге буенча «Фигуралы йөртү», «Юл-транспорт һәлакәтләре вакытында беренче медицина ярдәме күрсәтү», «Куркынычсыз тәгәрмәч», «Юл хәрәкәте иминлеге атнасы», «Юллар әлифбасы», «Кызыл, сары, яшел» смотр-конкурслары;

- ел саен май-июнь һәм июль-август айларында «Игътибар – балалар!» бөтенроссия операциясе уздырыла;

- районның күп кенә мәктәпләрендә яшь хәрәкәт инспекторлары отрядлары эшли.

Шулай итеп, әлеге 2 нче Ярдәмче программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру зарурлыгы түбәндәге сәбәпләргә бәйле:

проблеманың социаль-икътисади кискенлеге;

проблеманың тармакара һәм ведомствоара характеры;

федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый институтларны проблемаларны хәл итүгә җәлеп итү зарурилыгы.

Республика дәрәҗәсендә дәүләт ярдәме районда юл хәрәкәте иминлеге проблемаларын нәтиҗәлерәк хәл итәргә мөмкинлек бирә. Программа-максатчан методны куллану түбәндәгеләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк:

юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу сәбәпләрен тикшергәндә фәнни потенциалны үстерү һәм куллану, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләрен профилактикалауның һәм аларның авыр нәтиҗәләрен киметүнең төп һәм өстенлекле юнәлешләрен формалаштыру;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү;

зыян күрүчеләр булган юл-транспорт һәлакәтләре санын, шул исәптән профилактик характердагы, һәм юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар санын киметүче чаралар комплексын гамәлгә ашыру.

## II. 2 нче Ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары, аны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары, шулай ук үтәү барышын чагылдыручы максатчан индикаторлар һәм күрсәткечләр

2 нче Ярдәмче программаның максаты – юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә, шул исәптән балалар арасында үлем очракларын 2018 – 2020 елларга, 2012 ел белән чагыштырганда, 2,64 процентка  киметү.

Билгеләнгән максатка ирешү юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча бер-берсен тулыландыра торган өстенлекле бурычларны билгеләүгә системалы якын килүдән файдалануны күздә тота:

юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозуларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру максатында халыкка пропаганда йогынтысы системасын булдыру;

- балаларда юлларда куркынычсыз тәртип күнекмәләре формалаштыру;

машина йөртү культурасын күтәрү;

юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтүнең заманча системасын үстерү;

транспорт чаралары белән идарә итүгә хокук алу өчен машина йөртүчеләрне әзерләү таләпләрен һәм мондый әзерлекне гамәлгә ашыручы автомәктәпләргә карата таләпләрне арттыру.

2 нче Ярдәмче программаның бурычлары Россиядә юл-транспорт имгәнүләрен киметү буенча эшчәнлек юнәлешләренең һәм шул юнәлешләрдәге чараларның координацияләнгән системасын булдыруга мөмкинлек бирәчәк:

юл хәрәкәтендә катнашучыларның грамоталы, җаваплы һәм куркынычсыз тәртибе өчен шартлар;

ресурслар белән функциональ идарә итү принцибыннан конкрет эшчәнлек юнәлешләрен проектлы финанслауга күчү;

2 нче Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруга Россия Федерациясе субъектларын, муниципаль берәмлекләрне һәм дәүләтнеке булмаган оешмаларны актив җәлеп итү;

граждан җәмгыятен җәлеп итеп, дәүләт, муниципаль һәм шәхси секторларда кызыксынган барлык яклар катнашында хезмәттәшлек һәм партнерлык.

Гамәлгә ашыру еллары буенча 2 нче Ярдәмче программаның максатына ирешүне бәяләү 2 нче Ярдәмче программаның түбәндәге максатчан индикаторларын һәм күрсәткечләрен кулланып гамәлгә ашырыла:

юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны;

юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны;

социаль риск (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны – 100 мең кешегә);

транспорт рискы (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны 10 мең транспорт чарасына).

2 нче Ярдәмче программаның гамәлгә ашыру еллары буенча максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре 1 нче кушымтада китерелгән.

2 нче Ярдәмче программа 3 елга исәпләнгән.

## III. 2 нче Ярдәмче программа чаралары

2 нче Ярдәмче программа чараларын финанслау республика бюджеты һәм җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла. 2 нче Ярдәмче программаның чаралар комплексы программа юнәлешләре буенча капиталь кертемнәр һәм башка кирәк-яраклар өчен чыгымнар статьялары буенча формалаштырыла һәм финанслана.

Республика бюджеты акчалары исәбеннән 2 нче Ярдәмче программаны финанслау күләме прогнозланган характерда һәм төгәлләштерелергә тиеш, 2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы бюджетына 1,5 млн.сум күләмендә җирле бюджет акчалары салынган.

Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар санының күрсәткеч кыйммәтен анализлау, юл-транспорт һәлакәтләрен китереп чыгаручы факторлар буенча әлеге күрсәткечне структур анализлау һәм 2018 – 2020 елларга аварияләлек динамикасын фаразлау нигезендә, 2 нче Ярдәмче программаның Кукмара муниципаль районында юл-транспорт һәлакәтенә бәйле хәлне яхшыртырга сәләтле түбәндәге юнәлешләре билгеләнде:

балаларның хәвефсез юл хәрәкәтендә катнашуын тәэмин итү;

транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерү, юл шартларының куркынычсызлыгын арттыру.

Балаларның хәвефсез юл хәрәкәтендә катнашуын тәэмин итү буенча эшчәнлек балаларны һәм яшүсмерләрне юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү, балаларда юлларда куркынычсыз тәртип күнекмәләре булдыру, балаларның юл хәрәкәтендә катнашу дисциплинасын ныгыту һәм контрольдә тоту, балаларның юл хәрәкәтендә катнашуы өчен куркынычсыз шартлар тудыруны күздә тота.

Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерү, юл шартларының куркынычсызлыгын арттыру юнәлеше кысаларында эшчәнлек җәяүлеләрнең юл хәрәкәтендә хәвефсез катнашуын тәэмин итү, юл хәрәкәте куркыныч участокларының, бөкеләр һәм тоткарлыкларның барлыкка килүен бетерү һәм кисәтү, куркынычсыз һәм нәтиҗәле трафикны тәэмин итү максатыннан транспорт планлаштыруын оештыру, интеллектуаль транспорт системаларын үстерү, юллар һәм юл инфраструктурасының пассив һәм авариядән соң куркынычсызлыгын тәэмин итүне күздә тота.

2 нче Ярдәмче программаның транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерүгә, юл шартларының куркынычсызлыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралары 2 нче кушымтада китерелгән.

## IV. 2 нче Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

2 нче Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне планлаштырганда районның финанс-бюджет өлкәсендәге реаль хәл, аварияләлек торышы, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемасының югары икътисади һәм социаль-демографик әһәмияте, шулай ук аны республика ярдәме белән хәл итү мөмкинлеге исәпкә алынды.

2 нче Ярдәмче программа чараларын финанслау җирле бюджет акчалары хисабына башкарылачак.

Республика бюджеты һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән акчаларны тоту юнәлешләре буенча 2 нче Ярдәмче программаны финанслау күләме 3 нче кушымтада китерелгән.

Республика һәм җирле бюджетлар акчалары исәбеннән 2 нче Ярдәмче программаны финанслау күләме 4 нче кушымтада китерелгән.

Республика һәм җирле бюджет акчалары исәбеннән Программаны финанслау күләмнәрен аның дәүләт заказчылары арасында бүлү 5 нче кушымтада китерелгән.

Җәлеп ителә торган бюджет акчаларының төп өлешен, җәяүлеләр өчен, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, мәгариф учреждениеләренә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренә якын-тирәдәге көйләнми торган җәяүлеләр кичү юлларын, төзү, реконструкцияләү, техник яктан яңадан җиһазландыруны да кертеп, капиталь кертемнәргә, светофор объектларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазландыруга; торак пунктлар территорияләре буенча уза торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларында юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе урыннарын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан коралландыруга (ясалма яктырту җайланмалары), юл хәрәкәтендә катнашучыларның маршрут ориентировкасы системасын булдыруга (юл билгеләре, юл тамгалары урнаштыру) юнәлдерү күздә тотыла.

Республика бюджеты акчалары балалар белем бирү учреждениеләрен фәнни-методик һәм мәгълүмати материаллар белән тәэмин итүгә, юл хәрәкәте иминлеге буенча укыту семинарлары үткәрүгә, юл хәрәкәте иминлеге проблемаларына багышланган басма һәм видеопродукция булдыруга, яктылык кайтаручы элементлар сатып алуга һәм аларны белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалар һәм яшүсмерләр арасында таратуга юнәлдереләчәк.

## V. 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру белән идарә итү механизмын, җаваплылык өлкәсен бүлүне һәм 2 нче Ярдәмче программаның дәүләт заказчыларының үзара хезмәттәшлеге механизмын үз эченә алган 2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы программа чараларын нәтиҗәле башкаруны оештыру һәм көтелгән соңгы нәтиҗәләргә ирешүне контрольдә тоту инструменты булып тора.

Программаны тормышка ашыру белән идарә итүне оештыру формалары һәм методлары муниципаль заказчы – Кукмара шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Программаны тормышка ашыру буенча эшләрне оештыру белән Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы юл хәрәкәте куркынычсызлыгы комиссиясе (килешү буенча) шөгыльләнә.

Ярдәмче программа чараларын законда каралган тәртиптә төзелә торган контрактлар (шартнамәләр) нигезендә гамәлгә ашыру күздә тотыла. Программа буенча төзелә торган барлык объектлар да билгеләнгән тәртиптә программа объектлары реестрында теркәлә һәм исәпкә алына. Объектлар төзү процессы һәм контрактлар (шартнамәләр) буенча бюджет акчаларын тоту тәртибе Кукмара шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан контракт (шартнамә) төзегәннән алып һәм эшләрне тулысынча тәмамлауга кадәр контрольдә тотыла.

Программаны финанслау тәртибе һәм аны үтәүгә чыгымнарны, шулай ук бүлеп бирелгән акчалардан файдалану турындагы хисапны исәпкә алу Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнә. 2 нче Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тоту муниципаль заказчы тарафыннан башкарыла.

## VI. Программаның социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге юл хәрәкәтендә катнашучыларның тормышын саклап калудан, юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм аларның нәтиҗәләреннән социаль-икътисади һәм демографик зыяннарны булдырмаудан гыйбарәт. 2 нче Ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге аерым программа чараларының нәтиҗәлелеген интеграль бәяләү юлы белән билгеләнә, шул ук вакытта ирешелгән нәтиҗәләрнең куелган максатка һәм максатчан индикаторларның значениеләренә һәм 2 нче Ярдәмче программа күрсәткечләренең ирешелгән нәтиҗәләренә туры килү-килмәүдән чыгып бәяләнә.

2 нче Ярдәмче программаның нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы 2 нче кушымтада китерелгән.

2 нче Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге аның чараларын гамәлгә ашыруның республика бюджеты һәм җирле бюджетлар керемнәренә һәм чыгымнарына йогынтысын чагылдыра. 2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеге икътисадый һәм финанс күрсәткечләренең, шулай ук демографик хәлне яхшыртуга (үлем-китем санын, шул исәптән балалар үлеме санын киметү) һәм программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә халыкның үлеменнән килә торган социаль-икътисади зыянны киметүгә йогынты ясый торган күрсәткечләрнең яхшыруын характерлый торган сыйфатлы һәм күләмле параметрлар белән чагыштырыла.

2 нче Ярдәмче программаның экологик нәтиҗәлелеге юл-транспорт, бигрәк тә куркыныч йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары катнашында һәлакәтләр саны кимүгә китерә торган программа чараларын үтәү белән тәэмин ителә.

2 нче Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруның уңай социаль-икътисади һәм экологик нәтиҗәләре юл хәрәкәтен оештыруның яңа ысулларын гамәлгә кертүгә бәйле булачак. Оптималь маршрутларны куллану һәм юлда булу вакыты азрак булу хисабына углерод окисе һәм азот окислары чыгару кимиячәк, бу экологиягә уңай йогынты ясаячак.

2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗә программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм аларның нәтиҗәләреннән социаль-икътисади зыянны аны тормышка ашыру чыгымнарын исәпкә алып киметүдән гыйбарәт. Китерелгән социаль-икътисадый нәтиҗә гомуми эффектның бер ел эчендә дисконтлау коэффициентына мөнәсәбәте буларак исәпләнә. Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләгәндә, чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын исәпкә алып, 2 Ярдәмче программа чараларының бюджет керемнәрен формалаштыруга керткән өлеше бәяләнә.

2 нче Ярдәмче программа нәтиҗәлелеге исәп-хисапларында тиешле еллар бәяләре кулланыла, шул ук вакытта 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру чорында дисконтлау нормативы үзгәрешсез кала һәм 1,11 не тәшкил итә, инфляция дәрәҗәсе Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы мәгълүматлары нигезендә билгеләнә һәм Программаны гамәлгә ашыруның һәр киләсе елына индексацияләнә, ә зыян күләме нормативы юл-транспорт һәлакәтләреннән килгән социаль-икътисадый зыян нормативларын бәяләү һәм исәпләү методикасы нигезендә билгеләнә.

2 нче Ярдәмче программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген исәпләү 2 нче кушымтада китерелгән.

2 нче Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү 8 нче кушымтада китерелгән.

2 нче Ярдәмче программаның социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы 9 нчы кушымтада китерелгән.

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» 2 нче ярдәмче муниципаль программасына 1 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» 2 нче ярдәмче муниципаль максатчан программасының максатчан индикаторлары һәм күрсәткечләре**

| Аварияleлек күрсәткечләре | Үлчәү берәмлеге | 2012 ел | 2017 ел |
|---|---|---|---|
| Юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны | кеше | 15 | 4 |
| 2012 елга үзгәреш | процент | - | -14,33 |
| 2012 елга үзгәреш | кеше | - | 11 |
| Юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны | кеше | 0 | 0 |
| 2012 елга үзгәреш | процент | - | - |
| 2012 елга үзгәреш | кеше | - | 0 |
| Социаль риск (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны – 100 мең кешегә) | кеше | 8 | 7,72 |
| 2012 елга үзгәреш | процент | - | -3,5 |
| 2012 елга үзгәреш | кеше | - | 0,28 |
| Транспорт рискы (юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган затлар саны, 10 мең транспорт чарасына) | кеше | 22,5 | 22,43 |
| 2012 елга үзгәреш | процент | - | -0,33 |
| 2012 елга үзгәреш | кеше | - | 0,07 |

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» 2 нче ярдәмче муниципаль максатчан программасына 2 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру»**

**2 нче Ярдәмче муниципаль максатчан программасының республика һәм җирле бюджетлар акчалары һәм башка чыганаклар хисабына акчаларны тоту юнәлешләре буенча финанслау күләме**

(млн. сум, тиешле еллар бәяләрендә)

| N | Чаралар исеме | Үтәү вакыты | Финанслауның гомуми күләме – барлыгы | Финанслау | | | Җаваплы башкаручы | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | республика бюджеты акчалары хисабына | район бюджеты акчалары хисабына | бюджеттан тыш чыганаклар акчалары хисабына | | |
| Капитель кертемнәр | | | | | | | | |
| 1 | Җәяүлеләр өчен, шул исәптән мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, белем бирү учреждениеләренә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренә якын-тирәдәге көйләнми торган җәяүлеләр кичү юлларын төзү, реконструкцияләү; яктырту, ясалма юл тигезсезлекләре, светофорлар, т. 7 системалары, яктырту һәм светодиод индикациясе булган юл билгеләре, Г-образлы терәкләр, юл тамгалары, шул исәптән штучный формалы һәм төсле юл катламнары, ут кайтаргычлар һәм индикаторлар кулланып, | 2018 – 2020 еллар | 0,566 | | 0,566 | | Кукмара шәһәр Башкарма комитеты, ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча) | җәяүлеләр кичүендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | шулай ук өстәмә яктырту җайланмалары һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыруның башка элементлары белән яңадан җиһазландыру; техник яктан яңадан җиһазландыру | | | | | | | |
| 2 | Светофор объектларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яктан яңадан җиһазландыру | 2018 – 2020 еллар | 0,757 | | 0,757 | | | урам-юл челтәренең үткәрүчәнлек сәләтен арттыру |
| 3 | Юл хәрәкәтендә катнашучыларның маршрут ориентировкасы системасын булдыру (юл билгеләре урнаштыру, юл тамгалары кую) | 2018 – 2020 еллар | 0,177 | | 0,177 | | | хәрәкәт маршрутларын оптимальләштерү, экологик хәлне яхшырту, юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу куркынычын киметү |

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасына 3 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру»**

**2 нче ярдәмче муниципаль максатчан программасының республика һәм җирле бюджетлар акчалары һәм башка чыганаклар хисабына финанслау күләме**

(млн. сум, тиешле еллар бәяләрендә)

| № | | 2017 ел барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | Муниципаль берәмлек бюджеты | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар акчалары | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | барлыгы | шул исәптән чыгымнар статьялары буенча | | | барлыгы | шул исәптән чыгымнар статьялары буенча | | | барлыгы | шул исәптән чыгымнар статьялары буенча | |
| | | | | НИОКР | капиталь кертемнәр | башкалар | | НИОКР | капиталь кертемнәр | башкалар | | капиталь кертемнәр | башкалар |
| | Юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү системасын үстерү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | Балаларның хәвефсез юл хәрәкәтендә | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | катнашуын тәэмин итү | | | | | | | | | | | | |
| | Эксплуатацияләнә торган транспорт чараларының техник торышы, аларның актив һәм пассив куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | Транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын үстерү, юл шартларының куркынычсызлыгын арттыру | 1,5 | - | - | - | - | 1,5 | - | 1,5 | - | - | - | - |
| | Юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү системасын үстерү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекне норматив-хокукый, оештыру һәм методик тәэмин итүне камилләштерү | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы: | **1,5** | **-** | **-** | **-** | **-** | **1,5** | **-** | **1,5** | **-** | **-** | **-** | **-** |

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара ш.т. п. юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасына 4 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара ш.т. п. юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасын финанслау күләме

(млн. сум, тиешле еллар бәяләрендә)

| Финанслау чыганагы | 2018 – 2020 еллар |
|---|---|
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары, барлыгы, шул исәптән: | - |
| НИОКР | - |
| капиталь кертемнәр | - |
| башка кирәк-яраклар | - |
| Районның җирле бюджеты акчалары, барлыгы, шул исәптән: | 1,5 |
| НИОКР | - |
| капиталь кертемнәр | 1,5 |
| башка кирәк-яраклар | - |
| Бюджеттан тыш чыганаклардан, барлыгы, шул исәптән: | - |
| капиталь кертемнәр | - |
| башка кирәк-яраклар | - |
| Барлык чыганаклардан Программаны финанслау күләме, барлыгы | 1,5 |

«2018 – 2020 елларга Татарстан
Республикасы Кукмара муниципаль
районының Кукмара ш.т. п. юл хәрәкәте
иминлеген арттыру» муниципаль
максатчан программасына 5 нче кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара ш.т. п. юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасын муниципаль заказчылар арасында программаны тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчалар хисабына финанслау күләме бүленеше**

(млн. сум, тиешле еллар бәяләрендә)

| Программаның муниципаль заказчылары | 2018 – 2020 еллар | | |
|---|---|---|---|
| | НИОКР | капиталь кертемнәр | башка ихтыяҗлар |
| Кукмара шәһәр Башкарма комитеты | - | 1,500 | - |

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара ш.т. п. юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасына 6 нчы кушымта

**«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районындапоселогында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасы нәтиҗәлелеген бәяләү методикасы**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге методика «2018 – 2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасының (алга таба –2 нче Ярдәмче программа) нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү өчен билгеләнгән.

2. 2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге юл хәрәкәтендә катнашучыларның тормышын саклап калудан, юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм аларның нәтиҗәләреннән социаль-икътисади һәм демографик зыяннарны булдырмаудан гыйбарәт. 2 нче Ярдәмче программаның нәтиҗәлелеге Программаның аерым чараларының нәтиҗәлелеген интеграль бәяләү юлы белән билгеләнә, шул ук вакытта ирешелгән нәтиҗәләрнең куелган максатка һәм максатчан индикаторларның значениеләренә һәм Программа күрсәткечләренең ирешелгән нәтиҗәләренә туры килү-килмәүдән чыгып бәяләнә.

3. Әлеге методикада Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләүнең интеграль күрсәткече булып 2 нче Ярдәмче программа чараларын үткәрүдән Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру барышында булдырылмый калган зыян һәм республика бюджеты һәм җирле бюджетның суммар чыгымнары аермасы буларак билгеләнә торган икътисадый нәтиҗәлелек зурлыгы тора

II. 2 нче Ярдәмче программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен беренчел мәгълүматлар

4. Әлеге методикада 2 нче Ярдәмче программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге башлангыч мәгълүматлар кирәк:

а) программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә гомумиләштерелгән булдырылмый калган зыян;

б) максатчан күрсәткечнең факттагы кыйммәте һәм инерция сценариен үстергәндә күрсәткечнең кыйммәте арасындагы аерма (программа-максатчан метод булмаган шартларда);

в) республика бюджетының һәм җирле бюджетның гомумиләштерелгән һәм берләштерелгән чыгымнары.

## III. Китерелгән зыянның гомуми күләмен бәяләү

5. Прогнозланган максатчан күрсәткечнең санлы кыйммәтләре һәм программаның инерция сценариен үстергәндә (программа-максатчан метод булмау шартларында) күрсәткечнең кыйммәте программага 8 нче кушымтада китерелгән.

6. 2017 елда программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә гомумиләштерелгән булдырылмый калган зыянның гомуми күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_у = \sum_{i=1}^{8} P_{oi} ,$$

где $P_{oi}$ - i нче елда агымдагы бәяләрдә гомумиләштерелгән булдырылмый калган зыянның күләме.

7. i нче елда агымдагы бәяләрдә гомумиләштерелгән булдырылмый калган зыянның күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P_{oi} = \left(P_б \times K_{п1}\right) \times K_{дi} ,$$

биредә:

$P_б$ о – юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә 1 кешенең һәлак булуы хисабына Россия Федерациясе берләштерелгән бюджетыннан алып бетерелмәгән керемнең исәп-хисап күләме (сум);

$K_{п1}$ – максатчан күрсәткечнең факттагы кыйммәте һәм инерция сценариен үстерүдәге күрсәткечнең кыйммәте арасында аерма (программа-максатчан метод булмаган шартларда) (кеше);

$K_{дi}$ – база елына карата i нче елның фаразланган күрсәткечләр нигезендә билгеләнә торган индекс-дефляторы.

## IV. 2 нче Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыруга республика бюджеты һәм җирле бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү

8. 2 нче Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга республика бюджеты һәм җирле бюджет акчалары чыгымнарының нәтиҗәлелеген исәпләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Э = \frac{Р_у - З}{З} \times 100\%,$$

биредә:

$Р_у$ – 2018 – 2020 елларда 2 нче Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә гомумиләштерелгән булдырылмый калган зыян;

З – 2 нче Ярдәмче программа кысаларында 2017 елда республика бюджетының һәм җирле бюджетның гомумиләштерелгән һәм берләштерелгән чыгымнары.

## V. 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның Россия Федерациясе берләштерелгән бюджетын арттыруга йогынтысын бәяләү

9. 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен җирле бюджет акчаларын нәтиҗәле үзләштерү юл-транспорт һәлакәтләреннән һәм аларның район бюджетына китерелә торган нәтиҗәләреннән социаль-икътисади һәм демографик зыянны булдырмый калуга китерәчәк.

Фаразланган мәгълүматларга караганда, 2018 – 2020 елларда җирле бюджетларның чыгым өлеше структурасында 2 нче программаны тормышка ашыруга гомуми чыгымнар 2,0 млн.сум.

Шул ук вакытта мондый чыгымнар район бюджетының алып бетерелмәгән кереме рәвешендә 5,728 млн.сумга зыянны булдырмауга китерәчәк.

Шулай итеп, исәп-хисап буенча, 2017 елда 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсенә кертелгән инвестицияләрне кире кайтару 381,87 процент тәшкил итәчәк, бу исә 2 нче Ярдәмче программаны районның мөһим социаль-икътисади һәм

демографик бурычларын хәл итү буенча югары нәтиҗәле дәүләт проекты буларак характерлый.

«2017-2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара ш. т. п. юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасына 7 нче кушымта

**«2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасының социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенең исәп-хисабы**

| № | Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | 2017 ел |
|---|---|---|---|
| 1. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны (программа күрсәткече) | кеше | 4 |
| 2. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны (инерция сценарие – программа-максатчан метод булмаган шартларда ситуацияне үстерү) | кеше | 15 |
| 3. | Инерция сценарие белән чагыштырганда һәлак булучылар саны киму | кеше | 1 |
| 4. | Социаль-икътисадый зыян киму | млн. сум | 5,728 |
| 5. | Программаны тормышка ашыру чыгымнары | млн. сум | 2,000 |
| 6. | Инфляция индексы | - | 1,288 |
| 7. | Инфляцияне исәпкә алып чыгымнар | млн. сум | 2,29 |
| 8. | Социаль-икътисади нәтиҗә | млн. сум | 3,44 |
| 9. | Дисконтирование коэффициенты | - | 1,11 |
| 10. | Китерелгән социаль-икътисадый нәтиҗә | млн. сум | 3,1 |

«2018 – 2020  елларга Татарстан
Республикасы Кукмара муниципаль
районының Кукмара шәһәрендә юл хәрәкәте
иминлеген арттыру» муниципаль максатчан
программасына 8 нче кушымта

**«2018 – 2020  елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасының бюджет нәтиҗәлелеген арттыру исәп-хисабы**

| № | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | 2017 ел |
|---|---|---|---|
| 1. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны (программа күрсәткече) | кеше | 4 |
| 2. | Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булган затлар саны (инерция сценарие - программа-максатчан метод булмаган шартларда ситуацияне үстерү | кеше | 15 |
| 3. | Инерция сценарие белән чагыштыргнда һәлак булучылар саны кимү | кеше | 1 |
| 4. | Социаль-икътисадый зыян кимү | млн. сум | 5,728 |
| 5. | Муниципаль бюджет керемнәренә вклад | млн. сум | 1,3 |
| 6. | Программаны гамәлгә ашыруга муниципаль бюджеттан чыгымнар | млн. сум | 2,495 |
| 7. | Инфляция индексы | - | 1,288 |
| 8. | Инфляцияне исәпкә алып, муниципаль бюджеттан программаны тормышка ашыру чыгымнары | млн. сум | 1,94 |
| 9. | Бюджет нәтиҗәсе | млн. сум | -0,64 |
| 10. | Дисконтирование коэффициенты | - | 1,11 |
| 11. | Китерелгән бюджет эффекты | млн. сум | -0,58 |

«2018 – 2020 елларга Татарстан
Республикасы Кукмара муниципаль
районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру»
муниципаль максатчан программасына 9 нчы
кушымта

**«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ЮЛ ХӘРӘКӘТЕ ИМИНЛЕГЕН АРТТЫРУ» МУНИЦИПАЛЬ МАКСАТЧАН 2 НЧЕ ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ ҺӘМ БЮДЖЕТ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ**

1. Әлеге методика «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» 2 нче муниципаль максатчан ярдәмче программасының (алга таба – 2 нче Ярдәмче программа) социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү нигезләрен һәм алгоритмын билгели.

2. Әлеге методика ярдәмче программаның нәтиҗәлелеген исәпләүнең төгәл (каршы килми торган һәм хуҗалык итүче субъектларның икътисадый тәртибе кагыйдәләрен чагылдыра торган) методын тасвирлауны үз эченә ала.

3. Әлеге методика 2 нче Ярдәмче программаны эшләүдә, экспертизада һәм тормышка ашыруда катнашучы барлык милек формасындагы предприятиеләр һәм оешмалар өчен каралган.

4. Әлеге методика 2 нче Ярдәмче программаның аерым юнәлешләрен һәм чараларын эшләү һәм бәяләү буенча норматив методик документларны булдыру өчен нигез буларак кабул ителергә мөмкин.

5. Әлеге методика Россия Федерациясе Икътисад министрлыгы, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Россия Федерациясенең Төзелеш, архитектура һәм торак сәясәте буенча Дәүләт комитеты тарафыннан расланган инвестицион проектларның нәтиҗәлелеген бәяләү буенча методик рекомендацияләргә нигезләнә.

6. Бәяләр агымы 2 нче Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә агымдагы һәм киләсе чорларда тулай эчке продуктны арттыру буларак билгеләнә.

7. Саф бәя агымы аны тәэмин итү өчен кирәк булган чыгымнарны исәпкә кертмәгән бәя агымы буларак билгеләнә.

8. Бәяләрнең саф дисконтланган агымы база чорына китерелгән (дисконтлау коэффициентын исәпкә алып) саф бәя агымы булып тора.

9. Зыян күләме нормативы 2007 елдан 2010 елга кадәр куллану бәяләре индексын исәпкә алып билгеләнгән һәм 5,728 млн.сумга тигез итеп кабул ителә.

10. 2 нче Ярдәмче программа чаралары нәтиҗәләрен билгеләгәндә түбәндәгеләрне исәпкә алырга кирәк:

а) база чорында федераль бюджетның чыгым өлешенең тулаем эчке продуктка мөнәсәбәте;

б) тулай эчке продуктка турыдан-туры финанс кертеме;

в) тулай эчке продуктка репродуктив һәм мәдәни кертем;

г) бюджет керемнәрен формалаштыруга кертем.

14. Түбәндәгеләр көтелә:

а) тулай эчке продуктка турыдан-туры финанс кертеме 2 нче Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә тулай эчке продуктның кыйммәтен турыдан-туры арттыру буларак билгеләнә;

б) репродуктив һәм мәдәни кертем киләсе чорларда гамәлгә ашырыла һәм киләчәктә тулай эчке продуктның тиешле үсешен тәэмин итә. Шуңа бәйле рәвештә, аларның йогынтысын тулай эчке продукт үсешенең фаразланган темпларының бер өлеше буларак бәяләргә мөмкин;

в) тулай эчке продуктка агымдагы финанс, репродуктив һәм мәдәни кертем тулай эчке продуктта әлеге дәрәҗәдәге бюджетның агымдагы өлеше нигезендә бюджет формалаштыруга тиешле өлеш кертә.

12. 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеге, турыдан-туры финанс, репродуктив һәм мәдәни кертемнәрне исәпкә алып, бәяләрнең (тулаем эчке продуктка керткән өлешнең) саф дисконтланган агымы буларак билгеләнә.

13. 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан социаль-икътисадый һәм бюджет нәтиҗәлелеген исәпләгәндә, тулай эчке продуктны формалаштыруга файда һәм чыгымнар алучы субъектларга бүленмичә генә гомуми кертем бәяләнә.

14. Түбәндәгеләр көтелә:

а) 2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре үлчәнә, ягъни санлы аңлатма белән үлчәнә торган билгеле бер күрсәткече яки күрсәткечләр җыелмасы бар,

б) 2 нче Ярдәмче программа нәтиҗәләренең санлы кыйммәте тулай эчке продуктка кертем формалаштыруга бер үк төрле йогынты ясый, ягъни һәр чараның санлы нәтиҗәсе белән аның бәясен чагыштырырга мөмкин.

15. Дисконтлау коэффициенты 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты дәвамында үзгәрешсез кала.

16. Социаль-икътисадый нәтиҗә (саф дисконтланган бәя агымы) әлеге формула буенча билгеләнә:

$$NPV = \overset{T}{SUM}\frac{LN_T - \frac{C_T}{z^T}}{k},$$

биредә:

NPV – социаль-икътисади нәтиҗә (саф дисконтланган бәя агымы);

T – Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты (ел);

L – зыян күләме нормативы;

$N_T$ – 2 нче Ярдәмче программа нәтиҗәсенең сан ягыннан әһәмияте тиешле елда;

$C_T$ – 2 нче Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар, тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып;

$z^T$ – 2012 ел дәрәҗәсенә карата инфляция индексы;

к – дисконтлау коэффициентының даими зурлыгы.

17. Инфляция индексы 2012 ел дәрәҗәсенә карата түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$z^T = \prod_{2013}^{T}\frac{(100 + j)}{100},$$

биредә:

j – 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакытына инфляциянең фаразланган темплары (процент).

18. Социаль-икътисадый нәтиҗә 2 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә формалаштырылган саф бәя агымын формалаштыруга агымдагы кертемнән гыйбарәт.

19. 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның бюджет нәтиҗәлелеге 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә бюджет формалаштыруга кертемнең чиста дисконтланган агымы буларак билгеләнә. Аны исәпләгәндә, чыгымнарны исәпкә алып, 2 Ярдәмче программа чараларының бюджет керемнәрен формалаштыруга керткән өлеше бәяләнә.

20. 2 нче Ярдәмче программа чараларының бюджет керемнәрен формалаштыруга керткән кертеме тулай эчке продуктта бюджет өлеше буларак билгеләнә.

21. Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләп чыгарганда:

а) дисконтлау коэффициенты социаль-икътисадый нәтиҗәне исәпләгәндәге дисконтлау коэффициентына тигез кабул ителә;

б) инфляция темпы һәм индексы социаль-икътисадый нәтиҗәне исәпләгәндәге күрсәткечләргә тигез кабул ителә;

в) зыян күләме нормативы социаль-икътисадый нәтиҗәне исәпләгәндәге зыян күләменең нормативына тигез кабул ителә.

22. 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның бюджет нәтиҗәлелеге (бюджет формалаштыруга кертемнең саф дисконтланган агымы) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$NPV_b = \overset{T}{SUM} \frac{LN_T \times t - \left(\frac{C_{bT}}{z^T}\right)}{k},$$

биредә:

$NPV_b$ – 2 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның бюджет нәтиҗәлелеге (бюджет формалаштыруга кертемнең саф дисконтланган агымы);

t – база чорында (2010 ел) тулай эчке продуктта бюджетның исәп-хисап өлеше;

$C_{bT}$ – тиешле елларга бәяләр фаразын исәпкә алып, Программа чараларын тормышка ашыруга бюджет чыгымнары.

Бюджет нәтиҗәлелеге программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә формалашкан бюджетка саф кертем агымын формалаштыруга агымдагы кертемнән гыйбарәт.

Кукмара муниципаль районы
Башкарма комитетының _________
елның _____________ ______
номерлы карарына3 нче кушымта

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» Ярдәмче программасы

## ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» (алга таба – 3 нче Ярдәмче программа) |
| Заказчы – 3 нче Ярдәмче программа координаторы | Кукмара муниципаль районында терроризмка каршы комиссия |
| 3 нче Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты,<br>Кукмара муниципаль районында терроризмка каршы комиссия,<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге |
| 3 нче Ярдәмче программаның максаты | Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш һәм тынычлык дәрәҗәсен, Кукмара муниципаль районында экстремизмга һәм терроризмга каршы тору, профилактикалау һәм аларның күренешләрен кисәтү нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү; |
| 3 нче Ярдәмче программаның бурычлары | Милләтара һәм конфессиональара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ нигездә конфликтларны профилактикалау һәм булдырмау;<br>Халыкта терроризм һәм экстремизм идеологиясе күренешләренә түземсезлек атмосферасын булдыруга юнәлтелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру;<br>Терроризм һәм экстремизмка каршы юнәлдерелгән |

<table>
<tr><td></td><td>мәгълүмати-пропаганда эшчәнлеген көчәйтү</td></tr>
<tr><td>3 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары</td><td>2018 – 2020 еллар</td></tr>
<tr><td>3 нче Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td>3 нче Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабыннан 7 991,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br><br>(мең сум)<br><table>
<tr><th>Ел</th><th>ТР Кукмара муниципаль районының җирле бюджет акчасы</th></tr>
<tr><td>2018</td><td>2 368,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>2 248,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>3 375,0</td></tr>
</table><br>Искәрмә: финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>3 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре:</td><td>3 нче Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру терроризм һәм экстремизм күренешләренең барлык фактларына түземсезлек формалаштыруны камилләштерә;<br><br>Кукмара муниципаль районы территориясендә башка мәдәниятләргә карата толерантлык, хөрмәт идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыру;<br><br>Яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту;</td></tr>
<tr><td>3 нче Ярдәмче программаның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру</td><td>Кукмара муниципаль районында Терроризмка каршы комиссия 3 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тота.</td></tr>
</table>

**1. 3 нче Ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы**

3 нче Ярдәмче программаны эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен нигезне Россия Федерациясе Конституциясе, шәхес, җәмгыять һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге федераль законнар, 2009 елның 5 октябрендәге Россия Федерациясендә терроризмга каршы тору концепциясе, 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе дәүләт илкүләм сәясәте стратегиясе, шулай ук милләтара, диниара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән башка стратегияләр, концепцияләр, нигезләр тәшкил итә.

Кукмара муниципаль районы территориясендә терроризмга һәм экстремизмга каршы тору өлкәсендәге хәл тотрыклы кала һәм контрольдә тотыла. Район территориясендә 20 милләт вәкиле яши.

Районда 78 җирле дини оешма эшли: 73 мөселман (шул исәптән Кукмара мәдрәсәсе) һәм 5 православие мәхәлләсе. Теркәлгән чиркәүләрдә 2 гыйбадәт йорты һәм бер часовня эшли. Зур торак пунктларның храмнарында мәхәллә кешеләре өчен кичке һәм якшәмбе курслары эшли. Манзарас авылында 2 нче «Южный» мәчетен төзү планлаштырыла һәм Кукмара ш.Туеш микрорайонында яңа мәчет бинасы төзелеше тәмамланып килә. Мәчкәрә авылында 1791 елда төзелгән беренче җәмигъ мәчетен һәм Танькино авылында 1811 – 1822 елларда төзелгән Петр һәм Павел чиркәвен реставрацияләү дәвам итә.

Иҗтимагый-сәяси, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы, гомумән алганда, тотрыклы, дустанә, төрле социаль төркемнәр, милләт һәм дин вәкилләренең конструктив үзара бәйләнеше һәм хезмәттәшлеге белән характерлана. Экстремизм күренешләре күренми. Җирле халык традицион булмаган ислам тарафдарларына тискәре карый.

Шул ук вакытта җирле мөселман мохитендә Коръән тәгълиматындагы аермалар, мөселман йолаларын үткәрү тәртибе белән бәйле кайбер аңлашылмаучанлыклар бар, ләкинимамнарның күпчелеге традицион ислам карашларына ия һәм дин өлкәсендәге яңалыкларга тискәре карый.

Шуның белән бергә, 3 нче Ярдәмче программаны әзерләү һәм алга таба аны гамәлгә ашыру зарурлыгы Татарстан Республикасында терроризм һәм экстремизмка каршы көрәш өлкәсендәге хәзерге вәзгыять киеренкелеге белән бәйле.

Хәзерге вакытта терроризм һәм экстремизмга каршы көрәш практикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, иҗтимагый хәрәкәтләрнең һәм барлык гражданнарның тырышлыгын берләштерүне таләп итә.

Чараларны үтәү Кукмара муниципаль районы органнары алдында торган иң кискен проблемаларны, терроризмка каршы тотрыклылык дәрәҗәсен күтәрүнең уңай тенденцияләрен булдыру өлешендә хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк, бу исә гомуми иминлекне ныгытуга турыдан-туры йогынты ясаячак.

**2. 3 нче Ярдәмче программаның төп максатлары, бурычлары 3 нче Ярдәмче программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары.**

3 нче подпрограмманың максаты – Кукмара муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормыш һәм тынычлык дәрәҗәсен, экстремизмга һәм терроризмга каршы тору, профилактикалау һәм аларның күренешләрен кисәтү нигезендә законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау дәрәҗәсен күтәрү;

3 нче Ярдәмче программа максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

милләтара һәм конфессиональара татулыкны ныгыту, социаль, этник һәм конфессиональ нигездә конфликтларны профилактикалау һәм булдырмау;

халыкта терроризм һәм экстремизм идеологиясе күренешләренә түземсезлек атмосферасын булдыруга юнәлтелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру.

3 нче Ярдәмче программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

терроризмга һәм экстремизмга каршы тору һәм район территориясендә яшәүче гражданнар тормышын яклау;

толерантлык аңы һәм үз-үзеңне тоту нигезләре буларак гражданнарның хокукый культурасының тиешле дәрәҗәсенә ирешү;

яшьләр даирәсендә кеше хокукларын һәм иреген хөрмәт итү, этникара тынычлыкка һәм татулыкка омтылу принципларына нигезләнгән этномәдәни хөрмәт һәм рухи-әхлакый атмосфера формалаштыру.

3 нче Ярдәмче программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:

террорчылар һәм экстремистларны җәзалауның гадел чаралары буларак бәяләүче халык өлеше;

хокук саклау органнарының терроризм һәм экстремизм күренешләренә каршы көрәшнең тиешле чаралары буларак бәяләгән халык өлеше.

3 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру срогы – 2018 – 2020  еллар.

Төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук 3 нче Ярдәмче программада каралган чараларны финанслау күләме аңа кушымтада күрсәтелгән.

## 3. 3 нче подпрограмманы ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

3 нче Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты хисабыннан 7 991,9 мең сум тәшкил итә:

(мең сум)

| Ел | ТР Кукмара муниципаль районының җирле бюджет акчасы |
|---|---|
| 2018 | 2 368,0 |
| 2019 | 2 248,9 |
| 2020 | 3 375,0 |

Финанслау күләме фаразланган характерда һәм, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## 4. 3 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

3 нче Ярдәмче программаны әзерләүне планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияләүне һәм аларның үтәлешен гомуми контрольдә тота, ел саен 3 нче Ярдәмче программа чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, аны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын аныклый, чараларны үтәү өчен җаваплы затлардан, 3 нче Ярдәмче программаның үтәлеше турында мәгълүматларны соратып ала.

3 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру, аларны үтәү срокларын, бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру өчен җаваплы башкаручылар 3 нче Ярдәмче программаның заказчы-координаторына квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10 числосына кадәр чаралар үтәлеше һәм чараларны башкаручыларга тиешле бюджетлардан бүлеп бирелә торган акчаларның үзләштерелүе турында арта баручы нәтиҗә белән һәм тулаем алганда хисап елына мәгълүмат тапшыралар.

3 нче Ярдәмче программага үзгәрешләр кертү № нче Ярдәмче программа

чараларын җаваплы башкаручы тарафыннан билгеләнгән таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программа чараларының үтәлешен һәм финанс чараларын нәтиҗәле куллануны Кукмара муниципаль районының терроризмка каршы комиссиясе утырышларында, Ярдәмче программаны башкаручыларны тыңлап, даими рәвештә карау планлаштырыла.

**5. 3 нче Ярдәмче программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү**

3 нче Ярдәмче программа чараларын үтәү түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

терроризм һәм экстремизмны, радикаль дини агымнарны, ксенофобия күренешләрен, милли һәм раса түземсезлеген профилактикалау, территориядә этник дискриминациягә каршы тору буенча җирле үзидарә органнарының эш алымнарын һәм методларын камилләштерү;

терроризм һәм экстремизм күренешләренең барлык фактларына түземсезлек, шулай ук башка этник һәм конфессиональ берләшмәләр вәкилләренә карата толерантлык, уңай караш формалаштыру;

яшьләр арасында этникара татулык һәм толерантлык атмосферасын ныгыту һәм җәелдерү;

Кукмара муниципаль районы халкы арасында интернационализм, татулык, милли һәм дини түземлелек культурасын тарату.

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау» 3 нче Ярдәмче программасына кушымта

**«2018-2020 елларга Кукмара муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» ярдәмче программасы чаралары исемлеге**

| № т/б | Чаралары | Башкаручы (килешү буенча) | Үтәү вакыты | Финанслау ысулы, чыганагы | Еллар буенча бүлү, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2018 | 2019 | 2020 |
| | **БАРЛЫГЫ** | | | | | | |
| 1 | Подвал һәм чардак биналарының терроризмга каршы якланууын тикшерү буенча даими рейдлар үткәрү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | - |
| 2 | Кешеләр күп була торган биналарда гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта гамәлләр буенча уку дәресләре үткәрүне оештыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), ФГКУ «117 ТР буенча ФПС ПЧ (килешү буенча), РФ Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсенең Кукмара районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | - |
| 3 | Экстремизмның теләсә нинди формаларының, бигрәк тә милләтара һәм диниара дошманлык уятучы иҗтимагый куркынычын аңлату буенча барлык типтагы белем бирү учреждениеләрендә сыйныф сәгатьләрен системалы рәвештә | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе, Кукмара муниципаль районының дини конфессияләр вәкилләре (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге | 2018 – 2020 еллар, агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үткәрүне тәэмин итү | (килешү буенча) | | | | | |
| 4 | Терроризмны һәм экстремизмны, балигъ булмаганнарны, укучы яшьләрне экстремизм эшчәнлегенә җәлеп итүне кисәтү һәм аңа каршы тору буенча максатчан чаралар үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 – 2020 еллар, агымдагы елның июнь һәм сентябрь айлары | Район бюджеты | 10 | 10 | 10 |
| | | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге | | - | - | - | - |
| 5 | Яшүсмерләр арасында экстремизмны профилактикалау һәм аларны балалар һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегендә тормышка ашыру өлкәсендә программалар һәм проектларның республика конкурсында катнашу | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Мәдәният идарәсе, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар<br>ел саен | - | - | - | - |
| 6 | Кукмара муниципаль районы территориясендә терроризмга каршы көрәштә бердәмлек көненә багышланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы елның сентябрь ае | Район бюджеты | | | |
| | | Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, | | | 3,5 | 3,5 | 3,5 |
| | | Мәдәният идарәсе, | | | 3,5 | 3,5 | 3,5 |
| | | Мәгариф идарәсе | | | 3,5 | 3,5 | 3,5 |
| 7 | Терроризм һәм экстремизм күренешләренә каршы торуны пропагандалаучы квестлар, флешмоблар үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | |
| 8 | Экстремизмга каршы проблематика буенча иң яхшы журналист эше буенча ел саен үткәрелә торган конкурста катнашу | «Хезмәт даны» («Трудовая слава») район газетасы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Районның дини оешмаларында вәгазь һәм җомга намазлары вакытында дин тотучыларга дин тотучылыкны формалаштыруга һәм аңа ярдәм итүгә, шулай ук дин тотучыларда терроризм һәм экстремизмны конфликтлы ситуацияләрне хәл итүнең яраксыз ысуллары буларак бәяләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән системалы мөрәҗәгать башлангычы белән чыгу | Кукмара муниципаль районы дини һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү советы | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | - |
| 10 | Басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, укыту-методик әдәбият һәм башка басмалар материалларын аларда милләтара һәм төбәкара ызгыш-талаш уяту билгеләрен ачыклау буенча өйрәнү | Кукмара районы прокуратурасы (килешү буенча), Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге(килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | - | - | - | - |
| 11 | Яшьләр арасында экстремизм, ксенофобия, милләтара һәм төбәкара каршылык идеяләре таралуны кисәтү, шулай ук «Интернет» челтәренең төбәк сегментында экстремистик эчтәлектәге интернет-сайтларны үз вакытында ачыклау һәм булдырмау | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар | - | - | - | - |
| 12 | Кеше күп була торган объектларның, халыкның тормыш-көнкүрешен тәэмин | Кукмара муниципаль районының терроризмка каршы комиссиясе, Мәгариф, Мәдәният идарәсе, | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның | - | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | итү объектларының терроризмка каршы якланышы проблемаларын өйрәнү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | соңгы ае | | | | |
| 13 | Этникара хезмәттәшлекне, милләтара мәдәни элемтәләрне пропагандалау һәм ныгытуга юнәлдерелгән фото- һәм сәнгать күргәзмәләре уздыру | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2018 – 2020 еллар | - | - | - | - |
| 14 | Формаль булмаган берләшмәләрне ачыклау буенча рейдлар оештыру | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | - |
| 15 | Теркәлмәгән дини һәм милли берләшмәләрне ачыклау өчен, дини конфессияләр вәкилләре һәм милли диаспоралар вәкилләре белән әңгәмәләр үткәрү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча), Кукмара муниципаль районының дини һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү советы | 2018 – 2020 еллар | - | - | - | - |
| 16 | «Экстремизмга – ЮК!» айлыгы чорында чаралар үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы елның сентябрь ае | Район бюджеты | 5 | 5 | 5 |
| 17 | Программа чараларын мәгълүмати яктыртуны оештыру | «Хезмәт даны» («Трудовая слава») район газетасы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | - | - | - | - |
| 18 | Экстремизм эшчәнлегенә өндәүләр булган мәгълүматны ачыклау буенча Интернет сайтларга анализ үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | Район бюджеты | 40 | 40 | 40 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 19 | «Стрелец» ПАК системасына техник хезмәт күрсәтү | Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар | Район бюджеты | 2302,5 | 2183,4 | 3309,5 |

**2013 – 2018 елларга Россия Федерациясендә терроризм идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын үтәү кысаларында Кукмара муниципаль районы территориясендә терроризм идеологиясенә каршы тору чаралары**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 20 | «Хезмәт даны» («Трудовая слава») район газетасында терроризмны профилактикалау, тыныч милләтара һәм диниара мөнәсәбәтләр өчен шартлар тудыру мәсьәләләре буенча махсус чыгышлар бастырып чыгару | «Хезмәт даны» («Трудовая слава») район газетасы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | | |
| 21 | Белем бирү оешмаларында, мәдәният учреждениеләрендә, спорт комплексларында, иҗтимагый һәм дини оешмалар вәкилләрен чакырып, яшьләрдә милләтара һәм төбәкара толерантлык идеяләрен үстерү буенча мәдәни-агарту чаралары үткәрү | Мәгариф идарәсе, Мәдәният идарәсе, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | | |
| 22 | Терроризм һәм экстремизм юнәлешендәге җинаятьләр өчен хөкем ителгән затларны реабилитацияләү эшен оештыру | Кукмара муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | | |
| 23 | Кукмара муниципаль районы белем бирү оешмаларында «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика нигезләре» курсын укытуны анализлау | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | | |
| 24 | Терроризмга һәм экстремизмга каршы юнәлештәге нәфис һәм документаль фильмнар (шул | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы елның ярты | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | исәптән видеофильмнар) күрсәтү | | еллыгы буенча | | | | |
| 25 | Халыкның милли һәм дини традицияләрен саклап калу максатларында милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән мәдәни-агарту чараларын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе, Мәгариф идарәсе, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе, ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча), «Татмедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасы (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br><br>шәхси планнар буенча | | | | |
| 26 | «Терроризмга каршы торуның мөһим факторы буларак халыкара хезмәттәшлекне ныгыту» темасына күргәзмәләр, түгәрәк өстәлләр, семинарлар оештыру һәм үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе, Кукмара муниципаль районында Терроризмка каршы комиссия | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы елның ярты еллыгы буенча | | | | |
| 27 | Яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү, терроризм һәм экстремизм идеологиясенә каршы тору өлкәсендәге эш буенча квалификация күтәрүгә җибәрү | Кукмара муниципаль районы Советы, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф, Мәдәният идарәсе, Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенең кадрлар мәсьәләләре буенча җаваплы вазыйфаи затлары | 2018 – 2020 еллар<br><br>шәхси планнар буенча | | | | |
| 28 | Район халкының иҗтимагый фикерен өйрәнү максатыннан терроризмга каршы тору өлкәсендә социологик тикшеренүләр үткәрү | Кукмара муниципаль районының терроризмка каршы комиссиясе Кукмара муниципаль районының Иҗтимагый советы белән берлектә | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы елның ярты еллыгы буенча | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 29 | Дини оешмаларның эшчәнлеген Россия Федерациясе законнарына туры китерү (лицензияләү, теркәү) | Районның дини оешмалары | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |
| 30 | Яшьләргә гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә эш алып баручы яшьләр берләшмәләре эшчәнлегенә мониторинг үткәрү | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе; Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |
| 31 | Терроризм һәм экстремизм эшчәнлеген туктатырга карар кылган затларга тыныч тормышка җайлашуда ярдәм күрсәтү | Кукмара муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |
| 32 | Аерым игътибар категориясендәге затларның гаиләләренә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар | Кукмара муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |
| 33 | Аерым игътибар категориясендәге затларның балалары белән максатчан профилактик чаралар | Кукмара муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |
| 34 | Миграция агымнарын җайга салуга һәм мигрантлар арасында профилактик эш оештыруга юнәлдерелгән өстәмә чаралар кабул итү | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге (килешү буенча); | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |
| 35 | Район территориясендә яшәүче халыкларның дуслыгын ныгытуга юнәлдерелгән чара оештыру | Кукмара муниципаль районы башлыгы каршындагы Дини һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү | 2018 – 2020 еллар<br><br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | советы | | | | | |
| 36 | Терроризмны профилактикалау мәсьәләләре, гадәттән тыш хәлләр килеп туган очракта гамәлләр тәртибе буенча методик кулланмалар һәм белешмәлекләр тарату | Кукмара муниципаль районында Терроргa каршы көрәш комиссиясе каршындагы пропаганда төркеме | 2018 – 2020 еллар<br>агымдагы кварталның соңгы ае | | | | |

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору" программасына 4 нче кушымта ____________________ ел №______

2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында
халык арасында наркоманияне профилактикалау
Ярдәмче программасы

Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы халкы арасында наркоманияне профилактикалау» (алга таба – 4 нче Ярдәмче программа) |
| 4 нче Ярдәмче программаның муниципаль заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 4 нче Ярдәмче программаның төп эшләүчеләре | Кукмара районы эчке эшләр министрлыгы, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» муниципаль учреждениесе, «Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе |
| 4 нче Ярдәмче программаның төп башкаручылары | Кукмара муниципаль районы буенча Эчке эшләр бүлеге (килешү буенча);<br>«Кукмара үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;<br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МУ<br>«ТР Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МУ<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» МУ;<br>«Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча);<br>Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе |
| 4 нче Ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары | Наркотикларны законсыз тарату һәм медицинага кагылышсыз рәвештә куллану масштабларын киметү.<br>Хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен арттыру.<br>Наркотикларга бәйле кешеләргә дәвалау һәм реабилитацион ярдәм күрсәтү, туганнары белән психотерапевтик эш системасын камилләштерү.<br>Халыкта наркотик куллануга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыру.<br>Балаларны һәм яшьләрне кызыксынулары буенча берләшмәләрдә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү.<br>Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү. |

| | |
|---|---|
| 4 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программа чаралары исемлеге | Хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен активлаштыу.<br>2. Наркотикларга бәйле кешеләргә дәвалау һәм реабилитацион ярдәм күрсәтү, туганнары белән психотерапевтик эш системасын камилләштерү.<br>3. Халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып баруга юнәлеш һәм наркотиклар куллануга тискәре караш формалаштыру.<br>Балаларны һәм яшьләрне кызыксынулары буенча берләшмәләрдә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү.<br>5. Наркотик кулланучыларны комплекслы тернәкләндерү һәм ресоциальләштерү.<br>6. Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү. |
| 4 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | 4 нче Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>тикшерелгән наркоҗинаятьләрнең өлеше арту 100,5 процентка кадәр;<br>наркомания белән авыручылар контингентының артуы (ачыкланган һәм теркәлгән) 105 процентка кадәр;<br>наркотикларга каршы юнәлешле ата-аналар гомуми укыту программалары белән колачланган ата-аналар өлеше үсеше 105 процентка кадәр;<br>балалар һәм яшьләрнең гомуми исәбендә кызыксынулары буенча түгәрәкләрдә, физик культура һәм спорт, волонтерлык эшчәнлеге белән даими шөгыльләнүче балалар һәм яшьләр өлеше үсеше 105 процентка кадәр;<br>семинарларда һәм наркотикларга каршы юнәлештәге квалификация күтәрү курсларында белем алган белгечләрнең өлеше арту 110 процентка кадәр. |

## 1. 4 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру сферасының гомуми характеристикасы

## Төп проблемалар һәм аларны чишү юллары

Наркотик чараларның законсыз әйләнеше белән шөгыльләнүче затларны ачыклау, шулай ук әлеге линия буенча җинаятьләрне ачыклау буенча эшне активлаштыру максатыннан түбәндәге чаралар күрелгән:

- наркотикларның законсыз әйләнешенә катнашы булган затлар турында кергән оператив мәгълүматка анализ ясала.

- НОН һәм наркопритоннарны ачыклау буенча даими рәвештә максатчан рейдлар үткәрелә. Рейдлар үткәрү барышында элек хөкем ителгән, шулай ук элек законсыз рәвештә наркотик матдәләр кулланучы кешеләрне, наркотик матдәләр куллану фактына тикшерү үткәрелә, наркотик матдәләр җитештерү һәм куллануны ачыклау максатыннан Кукмара районы территориясендә урнашкан притоннар тикшерелә.

2017 елда наркотик чараларның законсыз әйләнеше буенча 6 җинаять теркәлгән, шул исәптән 2 се – наркотик матдәләр саткан, 2 се – законсыз саклаган һәм 1 се – наркотиклы үсемлекне законсыз рәвештә үстергән өчен.

Автомобиль хуҗалары арасында ЮХИДИ постларында автомашиналар белән идарә итүче затларның наркотик матдәләр куллану-кулланмавын тикшерү буенча оператив-эзләү чаралары үткәрелде. Әлеге фактларны ачыклаганда транспорт чаралары белән идарә итүгә чикләүләрне кую турында карар кабул ителә. 2016 елда машина йөртү таныклыгының 10 хуҗасына чикләүләр куелды, 2017 елда андыйлар юк.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының 2017 елның 9 июнендәге 428 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән, наркотиклы культураларның законсыз чәчүлекләрен кисәтү, ачыклау һәм бетерү, кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү урыннарына әзерләүчеләрнең керүен блоклау, шулай ук наркотик матдәләр җитештерүчеләрне, ташучыларны һәм сатучыларны табу һәм тоткарлау максатларында районда 2 этапта «Мәк-2017» ведомствоара комплекслы оператив-профилактик операциясе үткәрелде.

Әлеге операция кысаларында майлы мәк һәм киндернең законсыз чәчүлекләрен ачыклау буенча максатчан чаралар үткәрелде, аларны юк итү, шулай ук гаепле затларны җинаять яки административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрелде. «Мәк-2017» операциясе чорында 82 кв.м гомуми мәйданда гомуми авырлыгы 31,1 кг булган кыргый наркотиклы 388 куаклы үсемлек үсә торган 11 урын ачыкланды, наркокультураларны юк итү турында 15 кисәтү чыгарылды. «Мәк-2017» операциясе кысаларында үткәрелгән оператив-эзләү чаралары нәтиҗәләре буенча 1 җинаять эше кузгатылды.

Наркотик чараларны рекламалауны, аларны куллануны пропагандалауны ачыклау, наркотиклар һәм тарта торган катнашмаларны таратуга каршы тору максатларында эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан даими нигездә «Интернет» челтәренә мониторинг үткәрелә, нәтиҗәдә ачыкланган сайтларны блокировкалау буенча карар кабул итү өчен Роскомнадзорга җибәрелә. Хәзерге вакытта наркотик чараларны пропагандалау билгеләре булган 115 сайт ачыкланды һәм Роскомнадзорга җибәрелде.

## 2. 4 нче Ярдәмче программаның төп максаты, бурычлары. 4 нче Ярдәмче программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары.

4 нче Ярдәмче программаның максаты – наркотикларны законсыз тарату һәм медицинага кагылышсыз рәвештә куллану масштабларын киметү;

Ярдәмче программа максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча хокук саклау органнарының көчләрен арттыру;

наркотикларга бәйле кешеләргә дәвалау һәм реабилитацион ярдәм күрсәтү, туганнары белән психотерапевтик эш системасын камилләштерү.

халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып баруга юнәлеш һәм наркотиклар куллануга тискәре караш формалаштыру.

балаларны һәм яшьләрне кызыксынулары буенча берләшмәләрдә, физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү;

наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү.

4 нче Ярдәмче программа бурычларын хәл итү өчен түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру каралган:

хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешен кисәтү буенча эш нәтиҗәлелеген арттыру;

психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны дәвалау һәм реабилитацияләү системасын үстерү һәм камилләштерү;

халык, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру;

наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыру, норматив-хокукый һәм методик тәэмин итүне камилләштерү.

Программа чараларының нәтиҗәлелеген бәяләү өчен түбәндәге күрсәткечләрне кулланырга тәкъдим ителә:

наркоҗинаятьләрне тикшерүнең гомуми исәбендә авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрне тикшерү өлеше;

ачыкланган һәм теркәлгән наркомания белән авыручылар саны;

наркотикларга каршы юнәлешле ата-аналар өчен гомуми укыту программалары белән тәэмин ителгән ата-аналар өлеше;

балалар һәм яшьләрнең гомуми санына карата даими рәвештә түгәрәкләрдә физик культура һәм спорт, волонтерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче балалар һәм яшьләрнең өлеше;

наркотикларга каршы юнәлештәге семинарларда һәм квалификация күтәрү курсларында белем алган белгечләр өлеше.

4 нче Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру – 2018 – 2020 елларга исәпләнгән.

Төп максатлар, бурычлар, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, шулай ук 4 нче Ярдәмче программада каралган чараларны финанслау күләме аңа кушымтада күрсәтелгән.

### 3. 4 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру механизмы

4 нче Ярдәмче программаны әзерләүне планлаштыруны, үзара хезмәттәшлекне, координацияләүне һәм аларның үтәлешен муниципаль заказчы – 4 нче Ярдәмче программа координаторы гомуми контрольдә тота, ел саен 4 нче Ярдәмче программа чараларына максатчан күрсәткечләрне һәм чыгымнарны, аны гамәлгә ашыру механизмын һәм башкаручыларның составын аныклый, профилактика субъектлары һәм ведомстволарыннан – чараларны үтәү өчен җаваплы затлардан 4 нче Ярдәмче программаның үтәлеше турында мәгълүматларны соратып ала.

4 нче Ярдәмче программаны тормышка ашыру, аларны үтәү срокларын,

бюджет ассигнованиеләрен күрсәтеп, чаралар исемлеген үз эченә алган еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла.

4 нче Ярдәмче программага үзгәрешләр кертү Ярдәмче программа чараларының җаваплы башкаручысы тарафыннан гамәлгә ашырыла, яисә билгеләнгән таләпләр нигезендә Кукмара муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе тәкъдимнәрен үтәү йөзеннән башкарыла.

4 нче Ярдәмче программа чараларының үтәлешен һәм финанс чараларын куллануның нәтиҗәлелеген Кукмара муниципаль районының наркотикларга каршы комиссиясе утырышларда, профилактика субъектларын, Ярдәмче программаны башкаручы ведомстволар җитәкчеләрен тыңлап, даими рәвештә карау планлаштырыла.

## 4. 4 нче Ярдәмче программаның икътисадый, социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

4 нче Ярдәмче программа чараларын үтәү түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

районда легаль булмаган җитештерү, наркотиклар ташу һәм tарату инфраструктурасын юк итү юлы белән наркотиклар тәкъдим итүне кыскарту;

Наркотик, психотроп матдәләрне, аларның прекурсорларын, шулай ук көчле тәэсир итүче матдәләрне легаль әйләнештән законсыз әйләнешкә керүенә юл куймау;

наркотикларның яңа төрләре, шулай ук медицинадан тыш куллану өчен файдаланыла торган психоактив средстволар һәм психоактив матдәләр әйләнешенә чик кую;

профилактика, дәвалау һәм реабилитация эше системасын камилләштерү, шулай ук район халкының наркотикларны медицинадан тыш куллануга тискәре мөнәсәбәтен формалаштыру юлы белән наркотикларга ихтыяҗны киметү.

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы халкы арасында наркоманияне профилактикалау» 4 нче Ярдәмче программасына кушымта

# «2018 – 2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХАЛКЫ АРАСЫНДА НАРКОМАНИЯНЕ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ» 4 НЧЕ ЯРДӘМЧЕ ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | финанслау җирле бюджет хисабына сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2017 (База) елы | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| **I. Хокук саклау органнарының наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча көчләрен активлаштыру** | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| 1.1. Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләрне ачыклауга, булдырмый калуга һәм ачуга юнәлдерелгән оператив-эзләү чаралары үткәрергә. | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | наркоҗинаятьләрне тикшерүнең гомуми исәбендә авыр һәм аеруча авыр җинаятьләрне тикшерү өлеше, процент | 100 | 100,2 | 100,3 | 100,5 | - | - | - |
| 1.2. Наркотик, психотроп матдәләрне, аларның прекурсорларын, шулай ук көчле тәэсир итүче матдәләрне легаль әйләнештән законсыз әйләнешкә кертүне булдырмау буенча эшне оештырырга. | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | - | - | - |
| 1.3. Кыргый үскән һәм үстерелә торган наркотиклы үсемлекләр үсү урыннарын ачыклау һәм бетерү буенча оператив-профилактик чаралар комплексын гамәлгә ашыру («Мәк» операциясе). | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча), АЖ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (килешү буенча) | | | | | | | | | |
| 1.4. «Интернет» челтәре мөмкинлекләреннән киңрәк файдаланып, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча кабул ителгән ышаныч телефоннарының, кабул итү бүлмәләренең эш нәтиҗәлелеген һәм үтемлелеген арттырырга. | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 1.5. Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше фактлары турында гражданнардан килгән хәбәрләргә вакытында реакция белдерергә. | Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 1.6. наркологта исәптә торучылар исемлеген активлаштыру максатында «Кукмара РҮХ» ДАССУ белән системалы рәвештә тикшерүләр үткәрергә. | ОМВД (килешү буенча), «Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 1.7. Наркотик һәм алкоголь исереклегехәлендә транспорт чаралары белән идарә итүче затларны ачыклау буенча оператив профилактик чаралар үткәрү. | ЮХИДИ бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 1.8. Районга килгән чит ил гражданнары арасында наркотик чаралар, психотроп матдәләр, тәмәке катнашмалары законсыз әйләнешенә катнашы булган затларны ачыклау («Легаль булмаган мигрант» операциясе). | ОМВД (килешү буенча), ТР буенча УФМС Кукмара районындагы бүлеге (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| **II. Наркотикларга бәйле кешеләргә дәвалау һәм реабилитацион ярдәм күрсәтү, туганнары белән психотерапевтик эш системасын камилләштерү.** | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.1. . Наркотик һәм психотроп матдәләрне билгеләү өчен диагностик тестлар сатып алырга. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | ачыкланган һәм теркәлгән наркомания белән авыручы кешеләр саны арту | 100 | 100, 2 | 100, 3 | 100,4 | | | |
| 2.2. РҮХ табибларын халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, медицина практикасына дәвалауның заманча ысулларын кертү мәсьәләләре буенча квалификацияне күтәрү курсларында укыту. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| 2.4. Наркология кабинетына ремонт ясау. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 2.5. Клиентларга (психоактив матдәләр кулланучыларга) мәгълүмати һәм социаль хезмәтләр күрсәтү:<br>- медицина һәм социаль учреждениеләргә яңадан җибәрү һәм озата бару;<br><br>- Наркомания, ВИЧ һәм башка инфекцияләрне профилактикалау, социаль адаптация, шәхси мәсьәләләр буенча психологлар, табиблар, аларга тиң консультантлар тарафыннан мәгълүмат һәм консультация бирү. | ОСПСиД ГАУСО «КЦСОН «Тылсым» | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 2.6. « Тылсым» КЦСОН базасында наркотикларга бәйлеләргә һәм аларга бәйлеләргә социаль-психологик хезмәт күрсәтү | ОСПСиД ГАУСО «КЦСОН «Тылсым» | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.7. Наркотикларга бәйле кешеләрне тернәкләндерү курсын узуга мотивлаштыру | ЦРБ, ОМВД, ОСПСиД ГАУСО «КЦСОН «Тылсым» | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 2.8.. Эш урыннары булдырырга, дәвалау һәм тернәкләндерү курсы үткән наркотикларга бәйле кешеләрне эшкә урнаштырырга эш бирүчеләрне мотивлаштыру | ЦТиЗ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 2.9. Балигъ булмаган балалар тәрбияләүче наркотик кулланучы ата-аналарны ачыклаганда, алга таба ведомствоара учетка кую һәм гаиләдәге бәйле әгъзалары белән тернәкләндерү эшләрен үткәрү максатында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышында үз вакытында карарга кирәк. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча), ОСЗ (килешү буенча), УО, КДНиЗП | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | |
| **III. Халыкта сәламәт яшәү рәвешен алып баруга юнәлеш һәм наркотиклар куллануга тискәре караш формалаштыру.** | | | | | | | | | | |
| 3.1. «Уңышка юл» проекты кысаларында белем бирү учреждениеләрендә укучыларның ата-аналары белән наркотикларга каршы профилактик эш алып бару | Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар | агымдагы елда наркотикларга каршы гомуми белем бирү программаларында катнашкан ата-аналарның наркотикларга каршы программаларда катнашучыларның гомуми санына карата өлеше | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 3.2. «Белергә хокукым бар!» интернет- | Мәгариф | 2018 – 2020 | интернет- | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дәресләре уздыру | идарәсе | еллар | дәресләрдә катнашкан 9-11 сыйныф укучылары өлеше | | | | | | | |
| 3.3. Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллануны иртә ачыклау максатларында түбәндәгеләрне үткәрү: | | | | | | | | | | |
| 3.3.1. наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллану-кулланмауга социаль-психологик тест нәтиҗәләре буенча «риск төркеме» укучыларының, студентларның һәм призыв яшендәге затларның профилактик медицина тикшерүләре | «Кукмара РҮХ» ДАССУ, Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар | | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| 3.3.2. һөнәри эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыручы һәм наркомания белән авыручылар өчен чикләүләр билгеләнгән югары куркыныч чыганагы белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затларга наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллану-кулланмауга башлангыч (эшкә кергәндә) һәм периодик медицина тикшерүләрен үткәрергә; | «Кукмара РҮХ» ДАССУ, предприятие, учреждение һәм оешмалар җитәкчеләре | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 3.4. Өлкән сыйныф укучылары һәм студентлар өчен наркотикларга каршы профилактик спектакльләр күрсәтүне оештыру | УК, УО | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 3.5. Белем бирү оешмаларында, учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә тематик чыгышлар, лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ (килешү буенча), УО, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 3.6. Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләрендә профилактик эш оештыру:<br>- даими эшләп килүче китап күргәзмәләрен «Наркомания – дорога в никуда», «21 гасырда наркотикларсыз», «Яшьләр наркотикларга каршы» дигән | УК, ЦБС | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| яңа әдәбият белән тулыландыру<br>- «Без наркотикларга каршы!», «Полет и падение» стендларын һ. б. ясау<br>- китапханәләрдә «Тормышыңны җимермә», «Упкын янәшәсендә», «Яшьләр наркотикларга каршы» дигән буклетлар, «Бәла булмасын өчен» листовкаларын булдыру<br>- «Наркотикларсыз тормыш» айлыгын оештыруда һәм үткәрүдә актив катнашу, «Без тормышны сайлыйбыз!» акцияләрендә катнашу<br>- барлык китапханәләрдә дә тематик папкалар һәм картотекалар булдыру. | | | | | | | | | | |
| 3.7. «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасы битләрендә наркотикларга каршы район комиссиясе эшчәнлеген яктырту, шул ук мәгълүматны «Кукмара авазы» радиосында, kukmor-rt.ru сайтында кабатлау | «Татмедиа» Агентлыгы филиалы «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 3.8. Районда хокук саклау органнары, мәдәни-агарту, мәгариф учреждениеләре тарафыннан үткәрелә торган чараларны яктырту. | «Татмедиа» Агентлыгы филиалы «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасы редакциясе (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 3.9. «Без – сәламәт яшәү рәвеше өчен» | «Татмедиа» | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| рубрикасын булдыру һәм «Хезмәт даны» («Трудовая слава») район газетасында наркотикларга каршы тематика материалларын урнаштыру:<br><br>– «Без – сәламәт яшәү рәвеше өчен» махсус полосаларын әзерләү – айга 1 тапкыр.<br><br>– 26 июнь – Халыкара наркотик чараларны явыз ният белән куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш көненә багышланган материаллар әзерләү – елга 1 тапкыр.<br><br>– РҮХнең табиб наркологы белән интервьюны елга 1 тапкыр бастырып чыгару.<br><br>- ел дәвамында наркоманиягә һәм начар гадәтләргә тискәре караш турында балаларның иншаларын бастырып чыгару.<br><br>- kukmor-rt.ru сайтында ярты елга бер тапкыр сораштыру үткәрү | Агентлыгы филиалы «Хезмәт даны» («Трудовая слава») газетасы редакциясе (килешү буенча) | | | | | | | | | |
| 3.10. Наркотикларга каршы профилактика эшенә иҗтимагый оешмаларны, традицион конфессияләрнең дини берләшмәләре җитәкчеләрен җәлеп итәргә. | АНК | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 3.11 наркоманияне профилактикалауда социаль реклама, күрсәтмә агитацияне киң куллану. | Наркомания не профилактик алау субъектлары | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **ІУ. Балаларны һәм яшьләрне системалы дәресләргә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, физик культура һәм спорт, волонтерлар хәрәкәтен үстерү түгәрәкләрендә** | | | | | | | | | | |
| 4.1. Яшәү урыны буенча спорт секцияләрендә, иҗади түгәрәкләрдә, яшүсмерләр һәм яшьләр өчен булган мәнфәгатьләр буенча клубларда шөгыльләнүчеләр санын арттыру. Риск төркеменнән балаларны ДЮСШ, ДОО (П)Ц, КДШИ, яшүсмерләр клубларындагы занятиеләргә җәлеп итү | УО, УДМС, УК | 2018 – 2020 еллар | балалар һәм яшьләрнең гомуми исәбендә даими рәвештә түгәрәкләрдә физик культура һәм спорт, волонтерлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүче балалар һәм яшьләрнең өлеше, процент | 100 | 102 | 104 | 106 | | | |
| 4.2. Наркотикларга каршы «Мөстәкыйль балалар» проектын гамәлгә ашыру кысаларында районның белем бирү оешмаларына балалар һәм яшүсмерләрдә шәхси, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрне аңлауны стимуллаштыруга юнәлдерелгән методикалар кертү. | Мәгариф идарәсе | 2018 – 2020 еллар | Наркотикларга каршы «Мөстәкыйль балалар» проектын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары өлеше», % | 16 | 50 | 75 | 100 | | | |
| 4.3. Яшүсмерләр һәм яшьләр арасында агитацион-массакүләм чаралар үткәрү:<br><br>- «Сәламәт булу – модада!», «Живи ярко!» һ.б. район акцияләре;<br><br>- укучы яшьләр арасында «Студентлар кышы», «Студентлар көзе» үзешчән иҗат фестивальләре;<br><br>- КВН уеннары;<br><br>Бөтендөнья тәмәкесез көн кысаларында «Янгыра, минем гитара» гитара астында җыр башкаручыларның конкурс- | <br><br><br>УДМС, УК, УО<br><br>УДМС, УК<br><br><br><br>УК, УДМС, УО<br><br>УДМС, УК | 2018 – 2020 еллар | | 100 | 102 | 104 | 106 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| фестивале;<br><br>Яшьләр көненә багышланган чаралар;<br><br>- футбол буенча ишегалды һәм урам командалары арасында ярышлар;<br><br>- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча ирекле акцияләр;<br><br>- Республика көненә багышланган спорт-күңел ачу чаралары;<br><br>- җәйге чорда сәламәтләндерү лагерьларында наркотикларга каршы профилактик чаралар оештыру;<br><br>- яшьләр арасында минифутбол район ярышлары;<br><br>- тематик дискотекалар;<br><br>- Халыкара наркоманигә һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш көне, Бөтендөнья тәмәкесез көн, Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне кысаларында чаралар | УДМС, УК<br><br>УДМС, СП<br><br>УК, УДМС, УО, ОСЗ<br><br>УДМС, УК<br><br>УДМС, УК, УО<br><br>УДМС<br><br>Мәдәният идарәсе<br><br>УДМС, УК, УО, ОСЗ | | | | | | | | | |
| 4.4. Наркотикларга каршы эшчәнлеккә юнәлдерелгән проектларның республика конкурсларында катнашу (грантлар алу). | УО, УК, УДМС, ОСЗ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 4.5. «Наркотикларсыз тормыш» республика акциясе кысаларында | Наркомания не профилактик | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чаралар үткәрү. | алау субъектлары | | | | | | | | | |
| **V. Наркотик кулланучыларны комплекслы реабилитацияләү һәм ресоциальләштерү.** | | | | | | | | | | |
| 5.1. Наркотикларга бәйле кешеләрне тернәкләндерү курсы узарга мотивлаштыру | ЦРБ, ОМВД, ОСПСиД ГАУСО «КЦСОН «Тылсым» | 2018 – 2020 еллар | ачыкланган һәм теркәлгән наркомания белән авыручы кешеләр саны арту | 100 | 102 | 103 | 104 | | | |
| 5.2. Эш урыннары булдырырга, дәвалау һәм тернәкләндерү курсы үткән наркотикларга бәйле кешеләрне эшкә урнаштырырга эш бирүчеләрне мотивлаштыру | ЦТиЗ | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 5.3. Балигъ булмаган балалар тәрбияләүче наркотик кулланучы ата-аналарны ачыклаганда, алга таба ведомствоара учетка кую һәм гаиләдәге бәйле әгъзалары белән тернәкләндерү эшләрен үткәрү максатында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышында үз вакытында карарга кирәк. | «Кукмара РҮХ» ДАССУ (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча), ОСЗ (килешү буенча), УО, КДНиЗП | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 5.4. Элеккеге наркотикларга бәйле кешеләргә самореализация өчен шартлар тудыру:<br>-спорт, иҗат белән шөгыльләнүгә тарту. | УК, УДМС, ОСЗ (килешү буенча) | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| **VI. Оештыру, норматив-хокукый һәм методик яктан наркотикларга каршы эшчәнлекне тәэмин итүне камилләштерү** | | | | | | | | | | |
| 6.1. Халык арасында наркоманияне кисәтүгә юнәлдерелгән семинарларда, тренингларда, «түгәрәк өстәлләрдә» белгечләрнең катнашуы. | АНК, УО, УК, ОСЗ (килешү буенча), УДМС,»Кукмара РҮХ» ДАССУ | 2018 – 2020 еллар | наркотикларга каршы юнәлештәге семинарларда һәм квалификация күтәрү курсларында белем алган белгечләр өлеше | 100 | 102 | 103 | 104 | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | (килешү буенча), ОМВД (килешү буенча) | | | | | | | | | |
| 6.2. Наркотикларга каршы эшчәнлек белән шөгыльләнүче белгечләрне квалификация күтәрү курсларында укыту. | ОМВД (килешү буенча), «Кукмара РҮХ» ДАССУ (килешү буенча), ОСЗ (килешү буенча), УО, УДМС, УК | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 6.3. Җиһазлау<br>Республика шәһәрләре һәм районнары китапханәләренең наркотикларга каршы әдәбияты белән җиһазлау һәм аларда тематик күргәзмәләр үткәрне оештырыру<br><br>Район, авыл һәм мәктәп китапханәләрен наркотикларга каршы әдәбият белән тәэмин итү, тематик күргәзмәләр үткәрү. | Мәдәният идарәсе | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 6.4. Мәгариф учреждениеләрендә, предприятиеләрдә, оешмаларда һәм учреждениеләрдә наркоманияне профилактикалау буенча методик әдәбият һәм күрсәтмә агитация чаралары тарату. | АНК, УО, ИК, УДМС, предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләре | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |
| 6.5. kukmor-rt.ru сайтында социологик сораштыру оештыру һәм үткәрү | «Татмедиа» Агентлыгы филиалы «Хезмәт даны» («Трудовая | 2018 – 2020 еллар | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | слава») газетасы редакциясе (килешү буенча). | | | | | | | | | |

Кыскартулар исемлеге:
ОМВД – Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге;
СП – Кукмара муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитеты;
УДМС – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе;
УК – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе;
УО – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе;
АНК – Кукмара муниципаль районының наркотикларга каршы көрәш комиссиясе;
ОСЗ – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;
ЦБС (ҮКС) – Кукмара муниципаль районының Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы;
КДНиЗП – балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе;
УФМС – (ФМХИ) Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Кукмара районындагы бүлекчәсе

«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» программасына 5 нче кушымта ____________________ №______

**«2018 – 2020 елларга законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенә каршы тору һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлеген киметү» ярдәмче программасы**

Ярдәмче программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның исеме | «2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» (алга таба – Ярдәмче программа) |
| Ярдәмче программаның муниципаль заказчысы | Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Ярдәмче программаны төп эшләүчеләр | -Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге;<br>- ТР Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе;<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль |

| | |
|---|---|
| | районындагы социаль яклау бүлеге;<br>- «Кукмара районында халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» Дәүләт казна учреждениесе;<br>-Авыл һәм шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнары;<br>- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Эшмәкәрләрнең иҗтимагый советы |
| Ярдәмче программаның төп башкаручылары | -Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге;<br>- ТР Кукмара муниципаль районы Мәгариф идарәсе;<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кукмара муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге;<br>- «Кукмара районында халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» Дәүләт казна учреждениесе;<br>-Авыл һәм шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнары |
| Ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары | Ярдәмче программаның максаты – эшмәкәрнең һәм үзмәшгульлекнең статусын һәм иҗтимагый танылуын күтәрү, законсыз эшмәкәрлеккә һәм район халкының формаль булмаган мәшгульлегенә каршы тору һәм профилактика үткәрү.<br>Ярдәмче программаның бурычлары:<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын, шул исәптән социаль эшмәкәрлекне, Кукмара муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы үзмәшгульлек субъектларын үстерү өчен уңай шартлар тудыру;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шул исәптән Кукмара муниципаль районының социаль эшмәкәрлегенә ярдәм инфраструктурасын үстерү;<br>Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы |

| | |
|---|---|
| | оешмаларына шул исәптән Кукмара муниципаль районының социаль эшмәкәрлегенә адреслы финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру;<br>- потенциаль үзмәшгульләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, шул исәптән социаль эшмәкәрләр арасында мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм аңлату эше;<br>- законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенең тискәре образын һәм аны җәмәгать тарафыннан кабул итмәүне булдыру;<br>- яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү. |
| Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программа чаралары исемлеге | Эшмәкәрләрнең иҗтимагый советы белән берлектә законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенә һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлегенә каршы тору чараларын түбәндәгеләр ярдәмендә тормышка ашыруда актив катнашырга:<br>- эшчәнлекнең төрле өлкәләренең торышына мониторинг үткәрү;<br>- эшмәкәрлек эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә хуҗалык итүче субъектларга мониторинг;<br>-легаль булмаган эшмәкәрлек эшчәнлеге фактларын кисәтү буенча вәкаләтләргә ия дәүләт хакимиятенең контроль-күзәтчелек һәм хокук саклау органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлек һәм алмашу.<br>Бизнес үсеше өчен әзер инфраструктура булу.<br>Кече һәм урта эшмәкәрлеккә һәм үзмәшгульлеккә ярдәм итү программалары турында халыкка мәгълүмат бирү;<br>түбәндәгеләр ярдәмендә эшмәкәрнең имиджын популярлаштыру һәм күтәрү:<br>- район массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар, шул исәптән яшь эшмәкәрләр белән интервьюлар;<br>- реклама һәм агитация материаллары тарату;<br>-район яшьләренең яшьләр эшмәкәрлеген үстерү мәсьәләләре |

| | |
|---|---|
| | буенча бизнес-форумнарда һәм конференцияләрдә катнашуы;<br>- яшь эшмәкәрләрнең район җитәкчелеге һәм бизнесменнар белән очрашуларын оештыру;<br>- яшьләр даирәсендә уңышлы эшмәкәрләрне алга этәрү;<br>- яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлеге нигезләренә өйрәтүне оештыру һәм гамәлгә кую документларын эшләүдә ярдәм итү;<br>- хосусый инвесторларга яшь эшмәкәрләрнең бизнес-проектларын тәкъдир итүне тәэмин итү;<br>- эшмәкәрләргә дәүләт һәм шәхси структуралар тарафыннан күрсәтелә торган ярдәмнең төрле төрләрен алуда булышлык күрсәтү.<br>- район яшьләренең яшьләрнең лидерлык потенциалын үстерү буенча төрле республика проектлары һәм программалары конкурсларында, яшьләр өчен фестивальләрдә, конкурсларда һәм белем бирү чараларында («Эшмәкәрлек фабрикасы», «Яшь эшмәкәр») катнашуы;<br>Эшсезләргә юридик һәм практик мәсьәләләр буенча консультация бирү.<br>Белгечләрнең эшчәнлекнең конкрет төрләрен сайлаганда, базарны анализлаганда ярдәм итүе.<br>Коммерция эшчәнлеген оештыру мәсьәләләренә кагылышлы уку курслары үткәрү.<br>Эшмәкәрләр белән эшләүче дәүләт оешмалары турында мәгълүмат бирү.<br>Үз предприятиесе өчен кирәкле торак булмаган биналарны сайлап алуда һәм арендалауда ярдәм күрсәтү. |
| Ярдәмче программаны тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектлары – 1415 берәмлек;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләр саны, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, шул исәптән социаль |

| | |
|---|---|
| | эшмәкәрлек һәм үзмәшгульләр – 4658 кеше; |

Ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми характеристика

Кече һәм урта эшмәкәрлек, шул исәптән социаль эшмәкәрлек, Кукмара муниципаль районы (алга таба – КМР ) икътисадында зур роль уйный, аның үсеше икътисади үсешкә, базарны кирәкле сыйфатлы товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүгә, яңа өстәмә эш урыннары булдыруга йогынты ясый, ягъни күп кенә актуаль икътисадый, социаль проблемаларны хәл итә.

Эшмәкәрлеккә ярдәм итү эшмәкәрлек эшчәнлеген үстерү өчен уңайлы оештыру һәм икътисадый шартлар тудырудан гыйбарәт. Эшмәкәр үз максатларына – табышны максимальләштерүгә, инвестицияләрнең нәтиҗәлелеген арттыруга, рискны минимальләштерүгә, милекне һәм шәхесне яклауга һ. б. нәтиҗәле ирешә алырлык шартлар тудырырга кирәк.

КМР икътисады өчен кече компанияләр эшчәнлеге аның сыгылмалылыгын арттыруда мөһим фактор булып тора. Кече бизнесның үсеш дәрәҗәсе буенча КМРның үзгәрә торган икътисадый шартларга яраклаштыру сәләте бәяләнә.

2. Ярдәмче программаның төп максаты һәм бурычлары. Ярдәмче программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләрен тасвирлау, аны гамәлгә ашыру сроклары.

Ярдәмче программаның максаты – эшмәкәрнең һәм үзмәшгульлекнең статусын һәм иҗтимагый танылуын күтәрү, законсыз эшмәкәрлеккә һәм район халкының формаль булмаган мәшгульлегенә каршы тору һәм профилактика үткәрү.

Ярдәмче программа максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү кирәк:

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын, шул исәптән социаль эшмәкәрлекне, Кукмара муниципаль районы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлек алып баручы үзмәшгульлек субъектларын үстерү өчен уңай шартлар тудыру

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, шул исәптән Кукмара муниципаль районының социаль эшмәкәрлегенә ярдәм инфраструктурасын үстерү;

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасы оешмаларына шул исәптән Кукмара муниципаль районының социаль эшмәкәрлегенә адреслы финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру;

Потенциаль үзмәшгульләр һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, шул исәптән социаль эшмәкәрләр арасында мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм аңлату эше:

- законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенең тискәре образын һәм аны җәмәгать тарафыннан кабул итмәүне булдыру;

яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү.

Ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, шул исәптән социаль эшмәкәрлек субъектлары – 1415 берәмлек;

- кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә эшләүчеләр саны, шәхси эшмәкәрләрне дә кертеп, шул исәптән социаль эшмәкәрлек һәм үзмәшгульләр – 4658 кеше;

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру срогы 2018 – 2020 елларга исәпләнгән.

3. Ярдәмче программа чаралары.

Эшмәкәрләрнең иҗтимагый советы белән берлектә законсыз эшмәкәрлек эшчәнлегенә һәм халыкның формаль булмаган мәшгульлегенә каршы тору чараларын түбәндәгеләр ярдәмендә тормышка ашыруда актив катнашырга:

- эшчәнлекнең төрле өлкәләренең торышына мониторинг үткәрү;

- эшмәкәрлек эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә хуҗалык итүче субъектларга мониторинг;

-легаль булмаган эшмәкәрлек эшчәнлеге фактларын кисәтү буенча вәкаләтләргә ия дәүләт хакимиятенең контроль-күзәтчелек һәм хокук саклау органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлек һәм алмашу.

Бизнес үсеше өчен әзер инфраструктура булу.

Кече һәм урта эшмәкәрлеккә һәм үзмәшгульлеккә ярдәм итү программалары турында халыкка мәгълүмат бирү;

Түбәндәгеләр ярдәмендә эшмәкәрнең имиджын популярлаштыру һәм күтәрү:

- район массакүләм мәгълүмат чараларында басмалар, шул исәптән яшь эшмәкәрләр белән интервьюлар;

- реклама һәм агитация материаллары тарату;

-район яшьләренең яшьләр эшмәкәрлеген үстерү мәсьәләләре буенча бизнес-форумнарда һәм конференцияләрдә катнашуы;

- яшь эшмәкәрләрнең район җитәкчелеге һәм бизнесменнар белән очрашуларын оештыру;

- яшьләр даирәсендә уңышлы эшмәкәрләрне алга этәрү;

- яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлеге нигезләренә өйрәтүне оештыру һәм гамәлгә кую документларын эшләүдә ярдәм итү;

- хосусый инвесторларга яшь эшмәкәрләрнең бизнес-проектларын тәкъдир итүне тәэмин итү;

- эшмәкәрләргә дәүләт һәм шәхси структуралар тарафыннан күрсәтелә торган ярдәмнең төрле төрләрен алуда булышлык күрсәтү.

- район яшьләренең яшьләрнең лидерлык потенциалын үстерү буенча төрле республика проектлары һәм программалары конкурсларында, яшьләр өчен фестивальләрдә, конкурсларда һәм белем бирү чараларында («Эшмәкәрлек фабрикасы», «Яшь эшмәкәр») катнашуы;

Эшсезләргә юридик һәм практик мәсьәләләр буенча консультация бирү.

Белгечләрнең эшчәнлекнең конкрет төрләрен сайлаганда, базарны анализлаганда ярдәм итүе.

Коммерция эшчәнлеген оештыру мәсьәләләренә кагылышлы уку

курслары үткәрү.

Эшмәкәрләр белән эшләүче дәүләт оешмалары турында мәгълүмат бирү.

Үз предприятиесе өчен кирәкле торак булмаган биналарны сайлап алуда һәм арендалауда ярдәм күрсәтү.

**2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районында Ярдәмче программаның төп күрсәткечләре**

| № т/б | Күрсәткечләрнең исеме | Үлчәү берәмлекләре | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны, шул исәптән социаль эшмәкәрлек | берәмлек | 1383 | 1401 | 1415 |
| 2 | Шәхси эшмәкәрләрне һәм үзмәшгульләрне дә кертеп, кече һәм урта эшмәкәрлек өлкәсендә мәшгульләр саны | кеше | 4133 | 4592 | 4658 |